И.Ф.Фәттахов

# Язучы-публицист осталыгы серләре

**УДК 070**
**БК 76.01**

Казан (Идел буе) федераль университеты журналистика һәм социология факультетының укыту-методик комиссиясе (беркетмә № 4, 10.03.2011) һәм татар журналистикасы кафедрасы (беркетмә № 1, 03.09.2010), татар филологиясе һәм тарихы факультетының укыту методикасы һәм хәзерге татар әдәбияты кафедрасы (беркетмә № 2, 27.10.2010) утырышларының карары нигезендә басыла

*Фәнни редакторы*
филол. фән. докторы, проф. В.З.Гарифуллин

*Рецензентлары:*
филол. фән. канд., доц. Г.Р.Гайнуллина
филол. фән. канд., доц. Р.Л.Зәйни

**Фәттахов И.Ф.**
Язучы-публицист осталыгы серләре: журналистика факультеты студентлары өчен “XX гасырның II яртысында төбәк публицистикасы” махсус курсыннан уку ярдәмлеге. Казан: К(И)ФУ нәшр., 2011. 64 б.

Татарстан Республикасының халык язучылары, Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге ияләре Нурихан Фәттах, Мөхәммәт Мәһдиев һәм К.Гали, Г.Исхакый исем. премияләр лауреаты, әдип, галим Тәлгат Галиуллин иҗатлары мисалында язучы-публицист һөнәре серләре ачыла.

Югары уку йортларының “021400 Журналистика” белгечлегеннән (*журналист* квалификациясе) һәм “031300 Журналистика” әзерлек юнәлешеннән (*бакалавр* дәрәҗәсе) белем алучы студентларга тәкъдим ителә.

К(И)ФУ нәшрияте, 2011
Фәттахов И.Ф., 2011

**УДК 070**
**БК 76.01**

Печатается по решениям заседаний учебно-методической комиссии (протокол № 4 от 10.03.2011) и кафедры татарской журналистики (протокол № 1 от 03.09.2010) факультета журналистики и социологии, методики преподавания и современной татарской литературы (протокол № 2 от 27.10.2010) факультета татарской филологии и истории Казанского (Приволжского) федерального университета

*Научный редактор*
доктор филол. наук, проф. В.З.Гарифуллин

*Рецензенты:*
канд. филол. наук, доц. Г.Р.Гайнуллина
канд. филол. наук, доц. Р.Л.Зайни

**Фаттахов И.Ф.**
Секреты мастерства писателя-публициста: Учебное пособие для студентов факультета журналистики по спецкурсу “Региональная публицистика II половины XX века”. Казань: Изд-во К(П)ФУ, 2011. 64 с.

Раскрываются секреты ремесла писателя-публициста на примере творчеств народных писателей Республики Татарстан, лауреатов государственной премии им. Г.Тукая РТ Нурихана Фаттаха, Мухаммета Магдиева и лауреата премий им. К.Гали, Г.Исхаки, литератора, учёного Талгата Галиуллина.

Предназначено для студентов высших учебных заведений, обучающихся по специальности “021400 Журналистика” (квалификация *журналист*) и направлению подготовки “031300 Журналистика” (степень *бакалавр*). Может использоваться в учебном процессе вузов при подготовке преподавателей литературы и литературоведов.

Изд-во К(П)ФУ, 2011
Фаттахов И.Ф., 2011

**Эчтәлек**

Кереш.....................................................................................................5

I бүлек. Нурихан Фәттахның иҗат серләре..................................................6

II бүлек. Мөхәммәт Мәһдиевнең иҗат лабораториясеннән..........................8

III бүлек. М.Мәһдиевнең иҗат портретына эскизлар..................................13

IV бүлек. Көлә белеп көлә иде *(М.Мәһдиев әсәрләрендә юмор)*.................13

V бүлек. М.Мәһдиевнең публицистик осталыгы........................................30

VI бүлек. М.Мәһдиев дөньясына бер караш...............................................44

VII бүлек. Тәлгат Галиуллинның иҗат портреты.......................................45

# Кереш

Хөрмәтле студент!

Язучы-публицистның иҗат җимешләрен дикъкать белән тыңлаучы да, уңай бәяләүче дә, кирәк чакта тәнкыйтьләүче дә кирәк. Мәсәлән, 1956 елда Мәскәүнең Щепкин исемендәге театр училищесенә укырга кергән Фирдәвес Әхтәмова төркемдәше Туфан Габдулла улы Миңнуллин өчен шундый кеше булган.

"Фирдәвес ханымның холкы җайлы тоелгандыр, Туфан Миңнуллин язган бер хикәясен иң беренче аңа укый, аның күзләрендә сыный торган була.

– Тәнкыйть сүзләре әйтә идегезме Туфанга? – дип сорыйм да, Фирдәвес ханым елмаеп:

– Кая инде каршы әйтү, курка идем мин аңардан, – ди. – "Туфан, бастылармы хикәяңне?" – дип сорыйм да: "Юк!" – ди дә Туфан: "Басарлар әле, басмый кая китсеннәр!" – дип куя. Һәм чынлап та шулай булды..." (Галиев М. Бибидән – Бибинургача // Татарстан яшьләре. – 2009. – 17 окт.)

1990 елда, мин Арча районының Галиәсгар Камал исемендәге Сикертән тугызеллык мәктәбендә укыганда, "Яшь ленинчы" (хәзерге "Сабантуй") газетасының "Зирәкләр, тапкырлар клубы"нда (ЗТК) катнашып җиңү яуладым. Баш редактор Роберт Мөгаллим улы Миңнуллиннан "Рәхмәт хаты" һәм, күрәсең, Ат елы булганга елкы рәсеме төшерелгән берничә календарь алдым. Шатлыктан башым күккә тигән иде. Тагын да рухланып китеп, кулым каләмгә үрелде. Тугызынчы сыйныфны тәмамлаган шул җәйне "Ат язмышы" дигән беренче хәбәрем "Арча хәбәрләре" район газетасында басылып та чыкты. Шулай итеп, иҗат юлын сайладым һәм моңа һич үкенмим.

"Вакыты гаҗезем" ("Аптыраулы вакытым") шигырендә Г.Тукай үзенең иҗат процессын, иҗат лабораториясен тасвирлап болай дигән:

"Тапдисәм маузуг, язарга аптырыйм:
"Кай төшеннән мин моны (дим) ләктерим?"
Ул йозак төсле миңа, юк ачкычым,
Я биек сәт, юк менәргә баскычым.
Я көймә ул, юк янымда ишкәгем;
Шул рәвеш эчтә кала күп хисләрем".
(Сүзлек: *маузуг* – тема, *сәт* – койма.)

## I бүлек. Нурихан Фәттахның иҗат серләре

Язучы булыр өчен Ходай биргән сәләттән тыш, әдәбият дөньясына аяк басканда өлкән әдипләрнең дә җылы сүзе, хәер-фатихасы кирәк.

“Чыннан да, безнең халыкта элек-электән “Әби”, Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники, Сибгат Хәким кебек ярдәмчел һәм аңлы, киң күңелле кешеләребез булмаса, без, күрәсең, бүгенге көнебездә ирешкән нәрсәләрнең күбесеннән мәхрүм булган булыр идек.

Язучы булу өчен күп нәрсә таләп ителә. Моның өчен иң әүвәл табигый талант һәм тырышлык кирәк. Ләкин сине аңлаучы, кирәк чакта сиңа ярдәм кулы сузучы халкың, – әйе, халкың! – булмаса, ялгыз талант белән генә әллә ни ерак китеп булмый”, – дип язган Нурихан Фәттах “Үзем генә түгел” истәлегендә [1, 366].

Н.Фәттахка әнисе атны ярату, аңа хөрмәт белән карау хисен кечкенәдән сеңдергән. Нуриханның анасы – Нурттин кызы Салика – кияүгә чыгар алдыннан тегермәнгә килгән булачак ире Садырлиманны күреп, үзен дә, җирән атын да ошаткан. “...Шулай да гомере буена ул яратып, сагынып эткәйнең шул сөйкемле атын сөйләде. Атларга карата аның күңелендә искиткеч бер җылылык хисе бар иде. Күчтавылдагы тормышын искә төшергәндә генә түгел, Янтыкта үткән бала чаклары турында сөйләгәндә дә аның телендә гел атлар булды. Ул аларның төсен, буен-сынын, кыланышларын үзенчә матур итеп, сагышланып сөйли белә торган иде.” [1, 382]

Беренче әсәрен бастырганда язучының үзсүзле (яхшы мәгънәсендә), принципиаль булуы бик мөһим, чөнки яшь каләм иясенә, гадәттә, ясалма киртәләр куялар. Әйтик, Нурихан Фәттахка “Сезнеңчә ничек?” исемле тәүге романын бастыру җиңел булмаган.

“1955 елда мин беренче зур күләмле әсәремне тәмамладым. Романны иң элек Габдрахман Әбсәләмов укып чыкты. Ниндидер бер җыелышта ул мине мактап телгә алды. Шуннан соң яшь иптәшнең беренче романын башкалар да укыдылар, яраттылар, мактадылар, ләкин... бастырырга ашыкмадылар. Ни өчен дигәндә, романның телендә-стилендә “фольклор материаллары” кирәгеннән артыграк булып чыккан иде. Аннан соң авыл тормышын да автор үзенчәрәк тасвирлаган иде. Яшь иптәшкә романның телен беркадәр үзгәртергә, кайбер нәрсәләрне сызып ташларга киңәш иттеләр. Ләкин автор бернәрсә дә үзгәртергә теләмәде. Журнал редакторы Гази Кашшаф та алай артык күндәмнәрдән түгел иде. Романны бастырудан ул бөтенләй баш тартты һәм менә шунда Язучылар союзының ул чактагы председателе Гомәр абый Бәширов бар җаваплылыкны үз өстенә алып, романны шул көенчә бастыруга иреште.” [1, 364]

Аннары да аңа матур әдәбият дөньясы барлык ишекләрен тиз генә, җайлы гына ачмаган. Н.Фәттах “Сызгыра торган уклар” тарихи романының беренче өлешен төзәтеп, 19 (!) тапкыр күчереп язган.

“Мисал өчен “Сызгыра торган уклар” романының басылу тарихын искә төшерергә була. Роман “Казан утлары”нда инде китте дигәндә, тоткарланып калды. Мәсьәләне ачыклау өчен, ягъни редактор белән автор арасындагы бәхәсне хәл итү өчен Язучылар союзына мөрәҗәгать итәргә туры килде. Кульъязманы Союз идарәсе һәм редколлегия әгъзалары укып чыкты. Романны тикшерү өчен махсус утырыш җыелды һәм бер-ике кешене исәпләмәгәндә барлык язучылар авторны яклап чыктылар.

...язучыларның күпчелеге бездә татар әдәбиятының, татар культурасының үсүе өчен чын күңелдән янып яшәүче кешеләр. Уртак кайгыны, уртак мәнфәгатьләрне алар һәрвакыт үз кайгыларыннан, үз мәнфәгатьләреннән өстен куялар һәм кирәкле әсәр турында сүз барганда ныклык, принципиальлек күрсәтә беләләр. Моның шулай икәнлеген миңа берничә мәртәбә “үз җилкәмдә татырга” туры килде. Миңа өлкән буын каләмдәшләр дә, кордашлар да, шулай ук яшьләр дә, гомумән, күп булышлык күрсәттеләр...” [1, 365]

Яшь каләмчене иҗатка рухландыручы да, аңа илһам нуры өләшүче дә, кайвакыт иҗат стимулы тудыручы да бик кирәк. Мәсәлән, Нурихан Фәттах яза:

“...1940 елны, ахрысы, “Яшь ленинчы”да минем өч-дүрт юллык хәбәрем басылды. Ул чактагы куанычны хәзер инде сөйләп торуның кирәге юк, дип уйлыйм. Тик шунысын әйтмичә мөмкин түгел: бөтен мәктәптә бу үзенә күрә

бер вакыйга булды. Озын тәнәфестә бик күп укучыларны линейкага җыеп, завуч Баямый Мөслимов абый мәкаләне кычкырып укып чыкты.

Минем түбә күккә тиде. Ничектер бер җаен табып, кыюланып, мин Баямый абыйга моңарчы беркемгә күрсәтмәгән шигырь дәфтәремне бирдем. ...Шигырьләрне укып чыккач, минем белән сөйләшеп утырды, киңәшләр бирде.” [1; 362 б.]

## Кулланылган әдәбият


1. Фәттах Н.С. Сайланма әсәрләр: 5 томда. V т. К.: Татар. кит. нәшр., 2002. 400 б.


## Белемнәрне тикшерү өчен сораулар, мөстәкыйль эшкә биремнәр

1. Нурихан Фәттах иҗатының серләре нидән гыйбарәт?
2. Аның әдип буларак танылуына кемнәр булышкан? Ул нинди тормыш шартларында язучы булып формалашкан?
3. Авторның “Фест дисбесе” дигән фәнни-публицистик хезмәте белән танышыгыз.

## II бүлек. Мөхәммәт Мәһдиевнең иҗат лабораториясеннән

Булачак әдип күңеленә бала чакта ук, гадәттә, әнисе зур йогынты ясый, әдәби оетқы салып калдыра. Мәсәлән, анасы Рабига абыстайның кышкы озын кичләрдә күрше әбиләр белән бергә Кол Галинең "Йосыф кыйссасы"н көйләвен М.Мәһдиев тыңлап үскән (бу хакта ул "Торналар төшкән җирдә" лирик-документаль повестендә яза).

Язучыны әсәр язуга тирә-юньдә яшәүче кешеләр дә, аларның фикер һәм гамәлләре дә этәрә:

"Әгәр кешеләр миңа күпме әдәби материал биргәннәрен белсәләр иде, минем белән елмаеп кына, хәл-әхвәл сөйләшеп кенә яшәрләр иде. "Ах, кызганыч бәндәләр, кызганыч бәндәләр" – дигән Гафур Коләхмәтов." [1; 306 б.]

Язучыга әсәре өчен материалны тормыш үзе бирә, мәсәлән:

"9.II.1979

1970 елда ел башыннан мине бик каты кыйный башладылар. Бер мәкаләм өчен. Шуннан мин неблагонадёжныйлар исемлегенә кердем. (Хәзер ул мәкаләне рәхәтләнеп цитировать итәләр.) Шул елны әни бик каты авырый башлады. Саташа башлады... Шул чорда мин "Фронтовиклар" дигән роман яздым. Хәзер шуның икенче изданиесен әзерләп утырам – шаккатарлык! Ничек яздым икән? Әгәр мине тормыш шулай кыйнамаган булса, мин аны яза алыр идемме икән?.." [1; 306 б.]

Минемчә, М.Мәһдиевнең "Торналар төшкән җирдә" повестен иҗат итүе кызыклы, үзенчәлекле тарихка ия. Әсәрне язарга әзерлек менә ничек барган:

"IX. 1977

В.Солоухинның “Капля росы” дигән романын укыйм. Әгәр безнең авыл турында язсаң, болай булыр иде.

1. Бикерактан кайтканда, кышкы бураннарда Сафыйларның уты күренә иде. Сафый хатыны белән апасы юлда очрамый калмыйлар иде. Багана умарталар, комган белән җиләккә бару, савыт-саба юк, ул чишмә белән яши – рухи дөньясы. Иске мунчаларында җен бар, таллар утырта, кара чыршы, карга оясы, зирекләр, Югары су буенда ул утырткан таллар.

(Әсәрендә Сафый чишмәсен тасвирлаганда автор боларны тәфсилле куллана. – И.Ф.)

2. Гатият абзый, затлы рәвеш. Уральск тормышын сөйли, суыкта эскерт салганда үрдәк кыздырып ашау турында тәмләп сөйли, авызга егып салалар, ди.

Тәкә сөзгәнне шәпләп сөйли...

(Авылдашым тегүче Гатият абзыйның Җаекта яшәгәндә Г.Тукайга чалбар тегеп бирүен яза әдип. Әлеге тарихи-документаль мәгълүмат хакында автор үзенең бер мәкаләсендә тулырак сөйли. – И.Ф.)

3. Мәрфугатти. Җиләккә йөри. Аерым күлмәге бар.

(Шул рәвешле, автор безнең күрше Мәрфуга әби образын тудыра. – И.Ф.)

4. Зөлфия – талант. Газиз хатыны ничек кычыткан белән чакты. Юмартлыгы. Кыр үрдәге дип кеше үрдәген... Сугыш вакытында авырый башлады.

(Болар бар да дөрес, чөнки әбием Фәсәхәтбану да бу хәлләрне сөйли иде. – И.Ф.)

5. Хәдичәтти. Артистка. Мәгъсүмне мәче алырга чыгара. Мине яңа күлмәк кигәч. Мансур белән без көнбагыш башын урлагач, әни янына кереп... Ике малайсыз калды.

(Бусы да хак сүзләр. – И.Ф.)

6. Нотфи. Бездә кунак, әйдәгез.

(Нотфи – безнең авыл кешесе иде. – И.Ф.)

7. Әскый. Безнең ат сезнең келәттә юкмы? Әллә нинди көннәр булыр әле, Шәвәли... дип, бригадирны тынычландырып сүндерә, ут булып килеп кергәч.

(Әскый ага авылыбызның Түбән очында яшәгән, уллары – балта остасы иде. Шәвәли карт, чынлап та, сугыш вакытында безнең авылда бригадир булып эшләгән. – И.Ф.)

8. Хәлил абзый. Кибеттә кыяр тота, илле генә грамм кабып куя. Тегүче – военком, РИК председателе һ.б.

(Хәлил абзый Гөберчәк кибетендә сатучы булган. Ул, оста тегүче буларак, районның хәрби комиссары, башкарма комитеты рәисе һ.б. зур кешеләргә кием-салым теккән. – И.Ф.)

Бәрәңге черегәч – көне туры килмәде. Кайтып кергәндә, балалар койма өстендә бәрәңге боламыгы ашап утыралар. Малае алдынгы тракторист.

(Хәлил абзыйның улы Хәйбин исемле фронтовик иде, башта тракторчы, аннары гаражда механик һәм минем эти белән бергә газовик булып эшләде. М.Мәһдиев аңа багышлап “Исәнме, Кәшфи абый!” дигән повесть язды. – И.Ф.)

9. Насый, Биби. Берсе – историк, икенчесе – врач. Черемховода су кызыл. Бибинур – аяк бозылса, сыер бозауламаса һ.б.

(Әсәрнең “Черемховода су кызыл” дигән бүлегендә автор анда суның ни өчен кызыл төстә икәнлеген дә, Урал якларында яшәгән Насый абзый белән Бибинур апаның ачы язмышын да, авылдашларына карата кылган игелекләрен дә тасвирлап уза. – И.Ф.)

10. Безнең әни бөтен кешенең серен үзенә сеңдереп дөньядан китте.

(Язучының әнисе Рабига 1928 елга кадәр Гөберчәктә абыстай, ә аның ире Сөнгатулла – мулла булып торган, шуңа күрә Рабига әбине безнең авылда хөрмәт йөзеннән “абыстай” дип йөртәләр иде. Гыйлемле абыстай, әлбәттә, күпне белгән, укымышлы булган. – И.Ф.)

11. Әптел абзый. Каланчада Герман пленын сөйли.

(Чыннан да, туган авылыбызда бик биек янгын каланчасы бар иде. Әптел абзый янгын сүндерүче саналган. – И.Ф.)

12. Гәптрәкыйп. Баланы мичкә тыгу. Сәгыйдуллалар өендә җылавы. Сугыш вакытында миңа ипи ашатуы.

(Дөрестән дә, Гәптрәкыйп зәгыйфь бала булып туа, аны агач көрәккә салып, җылы мичкә тыгып алалар. Сабый чагында үлемнән исән калган шул малай сугыш чорында М.Мәһдиевкә ипи ашатып, аны ачлык патшасыннан коткарып калган. – И.Ф.)

13. Ат куу. Көлтә кертү. Болында беренче тапкыр печән чабу.

(Сугышка кадәр һәм сугыш чорында авыл малайлары җәйге төндә колхоз атларын ашатырга алып чыкканнар, атка төяп көлтә керткәннәр, печән чапканнар. – И.Ф.)

14. Клуб җимерелү.

(Сугыш чорында безнең авылда клуб җимерелү – тарихи факт. Икенче катта урнашкан башлангыч мәктәптә концерт әзерләүчеләр бию өйрәнгәндә клубның түшәм такталары төшә башлый. Паника вакытында дәррәү купкан

халык ишектән чыкканда туганыбыз Сәлимә әбинең кечкенә кызын таптап үтергән. – И.Ф.)

15. 1943 елда колхоз бәйрәме. Ногман, Нигаҗ биилләр.

(Ногман ага – безгә туган, чөнки хатыны Миңкамал безнең Фәһеметдин бабайның бертуган апайсы иде. Язучы Гариф Ахунов та әнисе ягыннан Ногман абзый белән туган иде, исән чакта аларга кайткалап йөрде. – И.Ф.)

16. Тупы урманы, юкәлек, ...төпкел арты, таллык юлы, чырагач, визир юлы, казган юл. Төп чыгару.

(Бездә тополь агачын *тупыл*, тополь урманын *тупы* урманы дип әйтәләр. Юкәлектә колхоз чүнлеге урнашкан иде, анда безнең Фәһеметдин бабай 40 елдан артык умартачы булып эшләде. Ул чүнлеккә эти мине дә, бала чагымда, күп тапкырлар алып менеп, яңа аерткан бал ашатты. Кызганыч, инде хәзер умарталык юк. Миңа таллык юлы шулай ук таныш. Безне пионер чакта Чырагачка алып менделәр. Визир юлы – минем өчен серле юл, чөнки аңа һаман да барып җиткәнем юк әле. Төп чыгару кебек авыр эш белән авылыбызның берничә буыны шөгыльләнгән. – И.Ф.)

***

Авылга бүре килүне язарга. Аннан ничек итеп мин бүре күрдем:

1. Борчак урлаганда – утлар.

2. Кәнүшни янында.

3. 9 бүре.” [1; 299-300 б.]

“Торналар төшкән җирдә” әсәре өчен әдәби материал җыйганда М.Мәһдиев үз көндәлегенә болай теркәп куйган:

“1943 елгы Арча-Күпербаш юлын язарга. Телефон баганалары ничек сызгыралар. Без әни белән печән сатарга килдек, чана тартып. Зәйнәпбикә апаларда ничек кундык, базарда чүмеч ала яздык. Кайтышлый Күпербашка кереп чәй эчтек. Юл буе телефон чыбыклары сызгырды, андый җил әле дә бармы? Шуны ишеткәнем юк...” [1; 304 б.]

Дөрестән дә, әдип телефон баганалары сызгырывын сурәтләгәндә бу мәгълүматны өлешчә кулланган.

Яки:

“Авыл турында язганда искә алырга: ...Зөлфия. Аның бөтен тормышын, булганлыгын, әдип-фольклорчы, табигать баласы икәнлеген, чыршы башыннан карга күкәе, җиләк җыю, кыр үрдәге тоту, әрекмән белән киенүе... һ.б., һ.б. Трагический финал.” [1; 306 б.]

Чыннан да, автор повестьнең “Зөлфия” исемле бүлегендә нигездә шушы әйберләрне тасвирлаган.

М.Мәһдиев оныткан кайбер моментларны “Торналар...”га өстәргә дип язып куйган: “1944 ел җәенең мул чирәмле Чөмә Елга ындыр арты. Мин әтинең башына җиткән председательнең өенә кермим, яшьтәш кереп катык ашап чыга. Мине кыстап карый – мин ач көе шул чирәмдә ятып торам. Керсәм, мине дә ашатырлар иде. Әмма мин ач, горур калдым. Шул вакытта минем ачлыкны теге явыз күрмәде, мин аны җиңдем.”

“Торналар...”га керми калган кызыклы күренешләр дә бар икән: “авыл хатынының кич токмач җәюе; катыклы аш ашаган мужикның капка төбенә чыгып утыруы; сыерга үгез ияргән, үгез озата кайткан; мужик сөенә – сыер кысыр калмаячак.

Кышкы кич – керосин лампасын кич утырырга әзерләү шатлыгы, поэтикасы.” [1; 316 б.]

Язучы “Бәхилләшү” моңсу повестен иҗат иткәндә үз көндәлегеннән мондый язманы файдаланган:

“Ач вакытта, гадәт буенча, озын тәнәфестә өйгә йөгереп кайттым. 2 нче класста укыйм, әти төрмәдә, әни 4-5 баланы туйдырырга тиеш. Беркем эшләми. Фашистик алым белән безне изәләр. Әни әҗәткә он эзләп чыгып киткән икән дә кайтып керде. Мин ишек янында сөялеп торам. Әни берни дә тапмаган. Шунда әни мине кочаклап елады, и бала, сиңа нәрсә ашатыйм инде мин, дип. Мин дә еладым да мәктәпкә кереп киттем. Башка көнне озын тәнәфестә өйгә кайтмадым. Проклятие Сталину! Кабәхәт, иблис.” [1; 304 б.]

## Кулланылган әдәбият

1. Мәһдиев М.С. Сайланма әсәрләр: 5 томда. V т.: хикәяләр, пьесалар, публицистик язмалар / Төз. Г.Хәсәнова. К.: Татар. кит. нәшр., 2009. 431 б.

## Өстәмә әдәбият

Ахунов Г.А. Авыл пәйгамбәре // Кеше китә – җыры кала / Төз.-ред. Л.Якупова. К., 1996.

Галиуллин Т.Н., Урманчиев Ф. Тормышның үзе кебек // Кызыл таң, 1972, 5 авг.

Галиуллин Т.Н., Урманчиев Ф. Радость сопереживания // Советская Татария, 1974, 6 янв.

Галиуллин Т.Н. Өлкәннәр // Т.Галиуллин. Дәгъва. К., 1995. 192-199 б.

Галиуллин Т.Н. Кояшлы иҗат // Кеше китә – җыры кала / Төз.-ред. Л.Якупова. К., 1996.

Тәлгат Галиуллин: Галим. Остаз. Язучы / Фән. мөх. Д.Ф.Заһидуллина. Төз. Н.М.Йосыпова. К.: “Идел-Пресс”, 2008. 256 б.

Галиуллин Т.Н. Мөхәммәт Мәһдиев дөньясы // Идел, 2010, № 4, 54-62 б., № 5, 60-72 б.

Гыйләҗев А.М. Тынычлану зарарлы // Казан утлары, 1983, № 2, 140-151 б.

Гыйләҗев А.М. Сайланып чыккан сүзләр...//М.Мәһдиев. Бәхилләшү. К.,1990, 633-639 б.

Мәһдиев М.С. Сайланма әсәрләр: 3 томда. III т. К., 1996. 576 б.

Миңнуллин Ф. Прозаның гражданлык йөзе//Ф.Миңнуллин.Якты юллар.К.,1975.95-101 б.

Миңнуллин Ф. Яшьлекне сагыну: М.Мәһдиевнең иҗат портретына эскизлар // Казан утлары, 1980, № 1, 130-134 б.

Миңнуллин Ф. Реаль хәлләргә күз салыйк // Ф.Миңнуллин. Затлылык. К., 1989. 144б.

Мостафин Р. Боз кузгала // Р.Мостафин. Алга барышлый. К., 1977. 69-71 б.

Мөхәммәдиев Р. Гадиләр, гадәтиләр... // Р.Мөхәммәдиев. Якутлар табыладыр вакыт белән (Бүгенге татар әдәбиятындагы эзләнүләр турында). К., 1983. 163-177 б.

Фаттахов И.Ф. М.Магдиев – публицист (1990-1995 гг.) // Тонус, 2009, № 17, С. 222-226.

Фәттахов И.Ф. Көлә белеп көлә иде (М.Мәһдиев әсәрләрендә юмор) // Мәгариф,1999,№4,22-23б.

Фәттахов И.Ф. Туксанынчы еллар әдәбияты (Анкетага җаваплар) // Казан утлары, 1999, № 11, 154-156 б.

Фәттахов И.Ф. Лирик повестьләр остасы (Татарстан халык язучысы М.Мәһдиевнең тууына 70 ел) // Мәгариф, 2000, № 12, 17-18 б.

Фәттахов И.Ф. XX гасырның 80-90 елларындагы татар повестенең жанрлык хасиятләре // Фән һәм тел, 2004, № 1, 17-22 б.

Фәттахов И.Ф. Безнең авылның энциклопедиясе // Фән һәм тел, 2005, № 3, 30-34 б.

Фәттахов И.Ф. Тематик һәм сәнгати төрлелеккә омтылып//Тонус, 2006, №14,171-176 б.

Хөсни Ф. Кешеләр, юллар, җырлар // Социалистик Татарстан, 1972, 1 июнь.

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар, мөстәкыйль эшкә биремнәр**

1. Мөхәммәт Мәһдиевнең иҗат лабораториясенә хас үзенчәлекләрне әйтегез.

2. Язучыга осталык каян килә? Язучы осталыгын барлыкка китерә торган эчке һәм тышкы факторларны санагыз.

## III бүлек. М.Мәһдиев иҗат портретына эскизлар

“*Сөт калыр, Ватан китәр!*” [1]
Дәрдмәнд.

Узган гасырның 80-90 елларында безнең прозада дәртләнеп һәм илһамланып иҗат иткән язучыларның берсе Мөхәммәт Мәһдиев иде. XX г. татар әдәбияты тарихына М.Мәһдиев исемле әдип *классик* булып кереп калды. 1981 елда “Казан утлары” журналы битләрендә уздырылган “Проблемаларның үзәгендә – кеше. Әдәбиятта яңалык тойгысы” дигән бәхәстә катнашып, “Кайчан безнең китабыбызны, Айтматов китаплары кебек, чиратка язылып укый башларлар?” [2] дигән риторик сорау куйган сүз остасының инде бүген үз әсәрләрен китапханәләрдә студент-аспирантлар чиратка язылып укыйлар. 1990 елда Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләгенә лаек булган М.Мәһдиев иҗаты, аерым алганда, “Бәхилләшү” повесте – әдәбиятыбыз казанышы. “Халык улы” язмасында аның иҗатын югары бәяләгән Татарстанның беренче президенты Минтимер Шәймиев хаклы: “Республикабыз районнарында йөргәндә мин әледән-әле Мөхәммәт Мәһдиевне хәтергә төшерәм. Татарстанның һәм аеруча авыл җиренең табигатен, ямьлелеген, авылда туып-үсеп тә күпләребез күрә, тоемлый алмаган матурлыгын тасвирлап бирүдә, белмим, аңарга тиңләшкән башка берәү булдымы икән?” [3; 7]

М.Мәһдиев алтмышынчы еллар ахырында әдәбиятка килә. Аның берничә кыска хикәясе “Казан утлары” журналының 1967 елгы 5 санында басыла.

Шул ук басмада, алтмыш сигезенче елның бишенче санында, Мәһдиевне язучы-прозачы итеп таныткан “Без – кырык беренче ел балалары” повесте дөнья күрә. Сугыш шартларында Ташлытау (хәзерге Үрнәк бистәсе, аннары Арчага күчерелгән) педагогика училищесендә белем алган егетләрнең интернаттагы яшәешен, дөньяны танып белергә, гыйлемгә омтылуын, гомумән, заман сулышын берсеннән-берсе кызыклы эпизодлар, тормыш детальләре, уникаль характерлар аша искитәрлек җанлы гәүдәләндергән, җор тел белән язылган җыйнак композицияле бу повестьне әдәби тәнкыйть татар прозасында бер яңалык буларак кабул итә. Тәнкыйтьче Фарваз Миңнуллин повестькә уңай бәя биреп, мондый фикер әйтә: “Без – кырык беренче ел балалары” – яшь аралаш көлеп язылган, көлке белән фаҗига чиратлашып килгән әсәр, үзгә бер сагыш, якты моң белән сугарылган әсәр. Мин аны яшьлекне сагыну җыры дип атар идем” [4].

Минемчә, иң катлаулы чорда авыл малайларының укуда тырышлыгын тәэсирле итеп тасвирлый алуы – Мәһдиевнең иҗади уңышы. Автор юморга бай теле белән вакыйгаларны сурәтләгәндә төгәллеккә, кыскалыкка ирешә, укучы игътибарын һәрчак тотып тора.

Популяр әсәреннән соң әдип тагын да рухланып иҗат итә. Тиздән илленче еллардагы авыл интеллигенциясе, мәктәп тормышы, укытучы-фронтовикларның укыту-тәрбия өлкәсендәге фидакарь хезмәте турында “Фронтовиклар” романы (1972) басыла.

Тематикасы буенча сугыш дәвере һәм аннан соңгы авыл кешеләрен үзәккә куеп, чорның иҗтимагый-сәяси, әхлакый-фәлсәфи проблемаларын анализлаган актуаль яңгырашлы, милли рухлы “Каз канатлары” (1974-1976) һәм сиксәненче еллар татар авылы чынбарлыгын күрсәткән “Мәңгелек яз” (1982) романнарын, “Кеше китә – җыры кала” (1958-1968), “Торналар төшкән җирдә” (1979), “Ут чәчәге” (1980), “Исәнме, Кәшфи абый!” (1982), “Бәхилләшү” (1985-1987) повестьләрен язып, укучының эчкерсез мәхәббәтен яулый. Әлеге мәгънәле әсәрләре белән Мәһдиев әдәбиятыбызның алгы сафына чыга.

М.Мәһдиев татар әдәбиятының меңъеллык традицияләре яктылыгында галим һәм язучы булып формалаша. Ул Г.Тукай, Г.Камал, Ф.Әмирхан, Дәрдмәнд, С.Рәмиев, Г.Ибраһимов, М.Гафури иҗатларын өйрәнгәч, 35 яшьтә генә әдәби мәйданга чын-чынлап аяк баса. Әлбәттә, аңа күпмилләтле совет һәм дөнья әдәбиятлары йогынты ясамый калмый. Мәсәлән, Т.Галиуллин “Кайда сез, Нәфисәләр?” мәкаләсендә [5] Мәһдиевнең “Торналар төшкән җирдә” повестен талантлы рус язучысы И.А.Бунинның “Антон алмалары” хикәясе белән чагыштырып, табигать гүзәллеген сурәтләү ягыннан

аваздашлык тоя. Бу фикерен профессиональ тәнкыйтьче “Кояшлы иҗат” истәлек-язмасында тагын бер кат заман рухында кабатлый: “Соңгы елларда, бигрәк тә тәненә яман чир үтеп кергәч, Мөхәммәт буй-сыны, чандырлыгы, туры аркасы, ап-ак чәче, тирәнгә урнашкан акыллы, мәгънәле күзләре, киләчәк кешесе булуы белән Хәсән Туфанга охшый барса, эчке бәйсезлеге, буйсынмас, баш бирмәс менәзе белән урысның бөек язучысы Иван Бунинны хәтерләтә” [3; 54].

М.Мәһдиевнең барлык әсәрләре *татар авылы, татар кешесе язмышы өчен борчылу хисе* белән сугарылган, чөнки коммунизм төзергә маташу дәверендә халкымның ун гасыр дәвамында тупланган рухи байлыгын туздыру – әдәп-әхлак кагыйдәләрен сызып ташлау, милләт сакчысы булган динен оныттыру – нәтиҗәсендә милләттәшләр күңеленең карала баруы әдипнең йөрәген яндырган. Татар авылының бүгенгесен уйлап көйгән, милләтнең киләчәге өчен кайгырып саргайган. Бу хакта ул “Бәхилләшү”дә җаны әрнеп, күңеле сулкылдап елап язды. Чыннан да, Фарваз Миңнуллин сүзләре белән әйтсәк: “Бәхилләшү” – авылның үткәнен һәм бүгенгесен, авылның авыллыгын, татарның татарлыгын күп еллар буе бөтен нюанслары белән сурәтләп килгән популяр язучының элекке әсәрләреннән үсеп чыккан повесть. Мең төрле җепләр белән ул М.Мәһдиевнең моңарчы язган барлык әсәрләренә (“...” һ.б.) тоташып, уралып, чорналып беткән. “Бәхилләшү” – моңарчы язылган әсәрләренең соңгы аккорды” [4; 79].

Повестенә М.Мәһдиев нигә моңсу исем сайлаган? Беренчедән, бәхилләшү – кыска, күпмәгънәле атама. Икенчедән, әсәрне укыганда әдипнең балачагы һәм яшьлеге үткән 30-50 еллар авылын сагынуы, онытылган гореф-гадәтләр, авылдашлары белән хушлашуы кебек мәгънәләр барлыгы аңлашыла, ягъни исем повесть эчендә дә кабатлана. “Уңышлы табылган исемдә автор әсәрнең темасын, идеясен әйтеп бирә. Исем метафора вазыйфасын да, фокус вазыйфасын да үти. Ул әсәрнең фокусы рәвешендә бөтен вакыйгаларны үзенә җыеп тора. Исем кыскарак һәм күпмәгънәлерәк булган саен яхшырак. Аның мәгънәләре әсәрдәге сүзләр, күренешләр, вакыйгалар белән бәйләнешкә кереп ачыла. Исемне автор әсәре эчендә кабатлый” [6].

Язучы сиксәненче еллар татар авылыннан исә туган як матурлыгы тапмаган, чөнки тирә-юньне – бәрәңге бакчаларын, капка-койманы – колорадо коңгызы баскан, ул авыл кешесенең икенче икмәген ашап, бәгырен телгәли. Күрше Казаклар авылының ындыр артыннан Гөберчәккә кайта торган юл буйлап Мөхәммәт ага улы Искәндәр белән велосипедларын җитәкләп җәяү атлаганда шытырт-шытырт китереп бәрәңге кортын

таптыйлар икән, ә велосипед шиннарының челтәрле сырларына сытылган колорадо коңгызы тулган.

М.Мәһдиев авыл һәм шәһәр тормышын күзәтә белгән: саладагы үзгәрешләрне тиз күргән, кала яңалыкларын вакытында ишеткән. Сиксәненче елларда модага кергән күренешне, ягъни авырлыкларга түзә алмыйча кайчандыр авылны ташлап чыгып китүчеләр әҗәл килгәч, мәетләрен туган авыл зиратына кайтарып күмәргә васыять әйтүләрен тасвирлап уза. Иң гаҗәбе шул – бу мәрхүмнәр арасында читкә киткәннән бирле бер генә тапкыр да туган җиренә эз басмаганнары бар икән! Автор фикеренчә, боларны бөтенләй гафу итеп булмый, чөнки балаларын татарча сөйләшергә өйрәтмәгәннәр, инде оныклары рус телендә генә аралаша һәм алар ичмасам елга бер мәртәбә авылга кайтып, әби-бабайлары күмелгән зиратка барырга кирәклекне, кабер өсләрен коелган яфрактан чистартып гөл утырту, чардуганнарын буяу, каберташларын яңарту, мәрхүмнәр рухына сәдака бирү һәм дога кылу, корбан чалдыру йолаларын һич белми. Кайберәүләр туган җиргә сирәк-мирәк кайткалый икән. Ахыр чиктә аларны кендек каны тамган газиз туган туфрак тарта, аның өч аршын җирендә мәңгелеккә калырга телиләр. Мәсәлән, авыл басуында яшел борчак ашап үскән Фәләхетдин армиягә алынгач, Мәскәү хәрби гарнизонында өч ел хезмәт иткән. Мәскәү өлкәсендәге бер шәһәрчектә ашханәдә пешерүче Валентина исемле рус кызы белән танышкан, бераздан аның телевизорлы квартирасына йортка кергән, “окрошка” дигән суык аш ашарга өйрәнгән.

“Ләкин... борчак басуыннан зур шәһәргә кисәк сикереш аның баш миенә авырга туры килгән” [7; 92] һәм Фәләхетдин эти-энисен дә, туган авылын да оныткан. Марҗага өйләнүен хәбәр итәр өчен, хатыны кушуы буенча гына авылга кайткан, картларга килен бүләкләрен тапшырган һәм икенче көнне генә бары тик урысча бер җөмлә әйткән:

“– Я ваш язык забыл, – ди. – Я женился, – ди, – скоро уеду от вас, – ди” [7; 93].

Күрше Масра авылыннан туганы Фәтхулла килеп, аны акылга утыртып китмәкче булган. Әмма файдасыз:

“– Син нәрсә... (боларын язып булмый), син нәрсә, ә? Син нәрсә? Атаң-анаң телен оныттыңмы? Нигезеңне оныттыңмы? Каян чыкканыңны оныттыңмы? Мин сине... Майть! Изәм мин сине! Сопляк! Үз телеңдә сөйләшергә хурланасыңмы?.. Майть! Үтерәм! Бетерәм мин сине, татар халкы моның өчен мине судка бирмәс! Ата-анаңны оныткан син падлаunion бетергән өчен миңа чуртым да булмас...” [7; 93].

Ирексездән Дәрдмәнднең шигъри юллары хәтеремдә яңара:

“Кил, өйрән, и туган, бер башка телне,
Бүтән телләр белү яхшы һөнәрдер.
Катыштырма вәләкин телгә телне,
Тел уйнатмак наданлыктан әсәрдер” [8; 77].

…Үләр алдыннан Фәләхетдиннең дә ана теле ачылган: хәл белергә килгән авылдашына “безнең авылның урман юлындагы басуда үскән бер генә учма яшел борчак” [7; 94] ашыйсым килә дип саф татарча ялварган, әмма карлы көз булганга туганы бу гозерне үти алмаган. “Бәхил булыгыз” [7; 95] дип җан биргән Фәләхетдин.

Авылларның бушап калуын сугыш нәтиҗәсенә генә бәйләп аңлатучылар ялгыша дип уйлаган автор, чөнки Бөек Ватан сугышыннан соң әле җәен су буйларындагы түгәрәк уеннар икешәр әйләнә, ә кышын клуб яшьләр белән шыгрым тулган. Ләкин авыл халкына хезмәт хакын акчалата түләмичә, таңнан алып Кояш баеганчы хезмәт көненә эшләтеп, көзен туярлык икмәк бирмәгәннәр. Шуңа күрә “Оргнабор” аша язылып, яңа завод-фабрикалар төзелешенә киткәннәр. Крестьянга 60 еллар башында паспорт бирелгәч, татар яшьләре дә колхоз “коллыгы”ннан калага агылган. Урбанизация үз чиратында бик күп авылларның юкка чыгуына төп этәргеч булды.

“Бәхилләшү” повестендә М.Мәһдиев туган авылы, нигезе, нәсел-нәсәбе, хезмәт сөючән авылдашлары белән бәгырьне өзгәләрлек итеп хушлаша: “Кабартмалар, коймаклар пешкән, көзге вак яңгырда ризык исе таратып утырган туган җирем, кан яңартып яткан элеккеге авылым, хуш!

Ул эскертләрне, ул ризыкларны, кырау төшкән бәрәңге сабагы, баллы салам исләрен сагынып яшәвемне гаеп итмәгез инде...” [7; 252].

Язучы сугышка кадәрге һәм аннан соңгы татар авылының көнитешен оста сурәтләп, аны йолалары, гореф-гадәтләре онытылган 70-80 еллар авылына шактый дәрәҗәдә каршы куйды. Алай гына да түгел, чагыштырма ысул ярдәмендә шул заман авылының элеккесенә караганда рухсыз булуын исбатлады һәм чорның динсезлек, әхлаксызлык, эчүчелек, зиначылык, технократизм чирләре белән авырый торган авылны тизрәк дәваларга кирәк дип чаң сукты.

М.Мәһдиев әсәрләрен җентекле өйрәнү аның иҗатына хас төп үзенчәлекләрне табарга мөмкинлек бирә:

– материал сайлау, аны сәнгатьчә сурәтләү ягыннан кабатланмас әдип;

– әсәрләрендә сюжет, төенләнеш, каршылык, иң югары нокта юк;

– бер вакыйгадан икенчесенә, геройдан геройга, чордан чорга, авылдан шәһәргә җиңел күчә, лирик чигенешләр еш ясый, психологик анализ алымына киң таяна;

– язу стилен гел үзгәртеп тора: йомшак яки усал, яки ачы көлә, лиризм, драматизм, реализм, гипербола, юмор, сатира, ирония, сарказм, гротеск кебек сурәтләү чараларын аралаштыра;

– иҗатыннан затлылык, зыялылык бөркелә, милли фәлсәфи фикерләү, татар моңы агыла;

– җете күзле, тынгысыз зат булуы, күзәтә белүе һәм күрү хәтеренең әйбәтлеге аркасында милли колоритлы образлар тудыра, чынбарлыкны дөрес чагылдыра;

– табигать хозурлыгын, хезмәт ямен тасвирлап кешенең әхлак-әдәбен тәрбияли;

– теленә сыгылмалык, терелек, моңсу, җиңел, йомшак юмор, ә үзенә зирәклек, тапкырлык, үткенлек хас. Татарстанның халык язучысы А.Гыйләҗев сүзләре белән әйткәндә: “Мөхәммәт Мәһдиевнең теле – Илһам Шакировның мәгърур тавышы, Рөстәм Яхинның музыкаль фантазиясе кебек сирәк очрый торган милли байлыгыбыз” [3; 28].

Мәһдиев чорның юньсез кешеләренә тискәре мөнәсәбәтен ачыктан-ачык белдерде – аларны сатира ярдәмендә тәнкыйтьләде. Ләкин автор дөньяны “юньле эчле кешеләр” алып бара, диде. Биредә әдип гыйбрәтле күзәтүе белән уртаклаша: *кырау төшкән бәрәңге сабагы исен иснәп үскән кешеләр* беркайчан да хөсетле, карак, тәртипсез булмыйлар. Адәм баласының әхлагын авыл тәрбиясе төзәтә алуга катгый дәлилләр китереп, ышандыра ул безне.

Автор 80 еллардагы шәһәр чынбарлыгын, кешеләрен белеп сурәтләде. Исерекләр фронтовикларның орден-медальләрен урлап сату, намуссызларның аларны сатып алуы һәм 9 Май көнне күкрәкләренә тагып урамга чыгуы булсынмы, поездда барганда ике кулсыз сугыш инвалиды Исламгалинең пиджак кесәсен чистарту булсынмы – болар җәмгыятьнең эчтән череп таркалуын дәлилли торган мисаллар. Мондый ямьсез күренешләр безнең көннәрдә бик ешайды.

Мәһдиев шәһәр хатыннарын авылныкылар белән чагыштырып, кызыклы күзәтүләр ясый: “Авыл хатыннары белән сөйләшеп утырырга яратам мин. Алар тәкәллефсез була. Аларның, күрешкән вакытта, күлмәкләрен дә, чәч-баш, кыяфәтләрен дә мактау мәҗбүри түгел. Ә шәһәр хатынына шул мактау сүзләрен әйтмичә кара. Бигрәк тә авылдан килеп шәһәрләшкәненә, һәр адымында дама-ханым булу сыйфатына берәр зыян килмәсен тагы дип һәр сулышын контроль астында тотып газапланып яшәүчегә. Авыл хатынының җилдә, кояшта янган беләк-муеннары да “загар”га керми; шуңа күрә аны телгә аласы түгел. Шәһәр “ханым”ының “загар”ын әйтмичә калып кара! Мәңгегә дошман итәчәк. Авыл хатыннарының арадан берсен аерып мактау

сүзе әйтәсең икән – рәхим ит, башкалар да шуңа кушылачак. Әмма инде шәһәр хатыннарыннан берсен аерып аның күлмәге, чәче, “загар”ы турында берәр мактау сүзе әйтәсең икән... Ходай сакласын. Тегесе, макталмаганы, үзеңә генә түгел, балаларыңа, оныкларыңа дошман булачак. Яки бакчадан бала җитәкләп кайткан таныш хатыннарның берсенең баласына мактау сүзе әйтеп, икенчесенекен күрмичә генә кал... Бөтен нәсел-нәсәбеңә дошман булачак. Авылда исә алай түгел” [7; 241].

Язучы бүгенге авылга демократия җилләре алып килгән Көнбатыш мәдәнияте йогынтысын да күреп ала: “Алты почмаклы нарат өйне, биек коймаларны дерелдәтеп, бөтен авылдагы кош-кортны өркетеп утыз өченче еллардагы гитлер-югенд маршы яңгырый иде.

Вир гейен нах остен
Мит унс гот...
(Без Көнчыгышка барабыз,
Аллаһ безнең белән. – Автор тәрҗемәсе.)

И, авыл... Сиңа да килеп кердемени инде бу чир? Тагынниләр генә күрәсең бар икән синең?” [7; 242]

Мәһдиев геройлары мескен түгел, авторның үзе кебек үк горур. Алар җор телле, кирәк чакта шаяртып, укучыны көлдерә дә беләләр, ә тиешле урында елаталар да... Тормышны яраталар, әйләнә-тирәдәгеләргә игътибарлы, яшәү мәгънәсен аңлап яшиләр. Шул ук вакытта язучы батырларның язмышын бәгыреңне телгәләрлек итеп тасвирлый, мәсәлән, “Бәхилләшү”дәге Исламгали дөнья ачысын күп татыган: сугышта ике кулсыз калган кеше Казан ортопедлары могҗизасыннан соң колхозда тракторчы булып эшли. Ике кулсыз килеш трактор йөртә алган Исламгали, аякларын кистергән очучы Алексей Мересьев (чын фамилиясе – *Маресьев*) шикелле, батырлык кылган дигән сүз бит инде бу. Берсе трактор, икенчесе самолёт белән идарә иткән. Аерма шунда ки, Исламгалинең куллары, ә Мересьевнең аяклары юк. М.Мәһдиевнең дә, Борис Полевойның да каһарманнары – кыю йөрәкле. Аларның урыннарын алыштырсаң да, бер-берсенең батырлыгын эшли алырлар сыман. Бусы – төп уртаклык.

Полевойның герое Алексей Петрович Мересьев кебек үк Мәһдиевнең Исламгали агае да чын кешеме? Автор аның образын тудырган дип әйтү әле геройның прототибы юклыгын инкарь итми. Реалист буларак, М.Мәһдиев тормышны һичкайчан бозып сурәтләмәде. Геройларының прототиплары фани дөньяда яшәделәр. Иҗат хыялы язучыга героен тасвирлаганда гипербола алымын кулланырга рөхсәт бирә. Полевой шикелле Мәһдиев тә шактый арттырган, әлбәттә. Әмма бу Исламгали образының сәнгатьчә эшләнешен,

эстетик кыйммәтен, укучыга тәэсир итү көчен һич киметми. Димәк, әдәби образның гомумилеккә ия булу сыйфатын исәпкә алсак, Исламгали чынбарлыктагы кешеме дигән сорау үзеннән-үзе юкка чыга.

Олы җанлы “Исламгали агай үзенең имәндәй таза, яшь килеш ике кулсыз калу фаҗигасен искә төшермәс өчен” [7; 6] сугыш гарасаты хакында беркайчан дөресен сөйләми. Фронттагы котчыккыч хәлләрне күреп, тетрәнеп беткән йөрәге башкаларныкын да җәрәхәтләргә теләми. Аның каравы, гел мәзәк сөйләп авылдашларының кәефен күтәрә, җанын дәвалый:

“– Танкка кадәр разведротада булдым мин. Мине фашистлардан белмәгән кеше юк иде. Гитлер әйткән ди, әллә ничә тапкыр: Мәскәүдән Левитанны, Беренче Украина фронтыннан Ягудинны тотып китерегез, һәр икесенең башына йөзәр мең марка акча түлим дип әйтеп әйткән, ди. Шуларны пирвый усакка асам дип әйткән, ди.

Хатын-кыз кызыксына:

– Ул йөз мең маркага нәрсә алып була? – дип сорый.

– Аңамы? – ди Исламгали агай бераз уйга калып. – Аңамы? Ике цетнер арыш (икмәксез ел), аннан килеп бер кибән печән (мал курмысы хәзерләү крестьянның үзәгенә үткән!). Аннан килеп ике пар күн итек. И һәм дә бер тальян гармун. Өстәмәсенә.

Халык аһ итә. Аның саен әңгәмә кыза гына” [7; 6].

М.Мәһдиев иҗаты социалистик реализм кысаларына сыймый. Халкыбызның фаҗигале тормышын, бер үк вакытта өметле язмышын үзәккә алуы белән аны “милли реализм” тарафдары дип атап булыр иде.

Мәһдиев тоталитар системаның ак тапларын “Без – кырык беренче ел балалары”, “Кеше китә – җыры кала”, “Фронтовиклар”, “Торналар төшкән җирдә”, “Исәнме, Кәшфи абый!” әсәрләрендә билгеле сәяси сәбәпләр аркасында тулысынча күрсәтә алмады, социаль мотивларны эчкә үк яшергән иде. 80 елларның икенче яртысында М.С.Горбачёвның үзгәртеп кору сәясәте чорны үзгәрткәч, “Бәхилләшү” повестендә үткәннәрне реалистик рухта сурәтләде. Авыл кешесенең тамагы кара ипигә дә туймаган бит утызынчы-кырыгынчы елларда. Ата-аналар балаларын хәер эстәргә чыгарудан бик курыкканнар. Ачлык мәҗбүр иткәч, капчыгын аскан Сәләхи кебек малайлар авыл буйлап он-бәрәңге сорап йөргәннәр. Мәктәп укучылары кырдан башак, коелган борчак, өшегән черек бәрәңге җыйганнар. Районнан килгән вәкаләтле вәкилләр сугылган ашлык эскертләрен сүттереп, атлы молотилкадан саламны кабат уздырганнар. 1936 елның язында колхозларда атлар кырылганнар. Татарлар икмәкле якларга – шахталарга, авыр сәнәгать төзелешләренә – гаиләләре белән күченеп киткәннәр. Шулай итеп, тарихи Ватаныннан колак

каккан халкыбыз Советлар иле буйлап таралырга мәҗбүр ителгән. Биредә Дәрдмәнднең “Без” шигыре искә төшә:

“Гасырлар кичте китте... кичте еллар!
Нәбиләр, падишаһлар сөрде дәуран...
Гомерләрдер күчеп кәрван вә кәрван,
Килеп кичте җиһандан канча илләр!..” [8; 21].

Автор “Бәхилләшү”дә сугыштан соң татар халкының берничә буыны калага китеп, авыллыгын – авылча яшәвен, ашавын, киенүен, хәтта авылча фикерләвен – тиз арада онытуын һәм шәһәрләшүен тасвирлый. Әти-әнисе, авыл мулласы кушкан саф татар исемнәре Габделхәмит кебекләргә ошамый башлады, искерде янәсе, орфоэпик һәм орфографик яктан әйтү-язу өчен җайсыз, озын тоелды, имеш. Алар татарча исемнәрен русчага алыштырдылар, мәсәлән: Әхтәмҗан – Жора, Фәния – Феня... Шул рәвешле, Казан һ.б. шәһәрләрдә яшәгән күп татарлар борынгы милли исемнәребездән ваз кичеп, заман шартларына җайлаштылар, урыска яраклаштылар һәм, ни кызганыч, урыслаштылар. Андыйлар халкыбызның кагылгысыз саналган балага исем кушу йоласына төкереп, ана телендәге үз исемнәрен кыскарттылар, сабыйларына заманча яңгырашлы, тик мәгънәсез исемнәр куйдылар. Яһүдин Габделхәмит Исламгали улы урынына “Ягудин Хэмид Галеевич” [7; 10] барлыкка килде, аның улы Рабис (“рабоче-крестьянское искусство”дан кыскартып ясалган) яки Сәмигулланың ташбаш малае Раскул (“раскулачить” сүзеннән) шикелле *маңкортлар*, ягъни үз теленнән, диненнән, халкыннан аерылган *куркыныч* затлар үсеп чыкты.

Татар халкының гасырлар буе җыелган рухи тәрбия мирасын белмәү һәм өйрәнмәү сәбәпле, мәхәббәт җимешләрен советча тәрбия кылдылар. Нинди генә тәрбия ысулларын кулланып карамадылар!!! Габделхәмит Рабисны япон методикасы буенча тәрбияләүгә күчә һәм оныкүз галәмәтләре аркасында Исламгали бабайсын йөрәк өянәге алды хәләтенә китереп җиткерә. Габделхәмит шәһәрдә яшәп, бермәлне ана телендә дөрес итеп хат яза белми башлый: “*Көннәр эчендә чираттагы ялымны* алырга уйлыйм... Моннан *өч атна арттан* яңа квартирага күчтек, дүрт бүлмәлегә... Әле *ун көн генә арттан* туйда булдык: минем *шефның* малае *гаилә теркәде...*” [7; 15].

Шулай итеп, М.Мәһдиев Габделхәмитләрдән көлгән. Әле XX г. башында ук Дәрдмәнд мондый бәндәләрне күреп, болай язган:

“Урысча күп сүзең, азы татарча,
Белалмыйм, кем син – урысмы, татармы?
Ничектер белмәдек исме шәрифең:
Хәсәнме, юкса Иванмы, Макармы?..” [1; 102].

Ниһаять, 70-80 елларда Габделхәмит шикелле татарларның балалары тулысынча урыслашты: татар авылларына җәйге каникулга кайткан кызлар-малайлар рәхәтләнеп русча сиптеләр генә... Әби-бабайлар исә оныклары белән туган телдә чын күңелдән сөйләшә алмыйча интектеләр. Калада “татар” балалары мәктәптә дә, урамда да, хәтта гаиләдә дә рус телендә аралаштылар. Нәтиҗәдә Ватанын, җир-суын югалткан милләтебез бетүгә йөз тотты, ягъни “сөт” бозылды, ачый башлады... Шагыйрь әйтмешли:

“Сүнеп, вәйран булып мәгъмур тиякләр,
Җир астына тезелде ку сөякләр!..
Исә җилләр, күчә комнар... бетә эз...
Дәрийгъ, мәхзүн күңел, без дә бетәбез!” [8; 21].

XX йөздә татар халкының һөнәрчеләре белән бергә һөнәрләре дә онытылды. Мәсәлән, “Бәхилләшү”дәге гомере буе шәһәрдә имән мичкә ясаган Сәмигулла хәзер имән дә, “кәҗә маеңны чыгара” [7; 24] торган эшкә өйрәнүче яшьләр дә юк дип зарлана. Аныңча, Казанда бондарь профессиясен белүчеләр сиксәненче еллар башына бармак белән генә санарлык калган. Авылда исә һөнәр ияләре үзләре белән күпме серне алып китте икән?! Салада бүген чүлмәк, кирпеч сугучылар, арба-чана ясаучылар, мич чыгаручылар, итек басучылар бетте.

Йомгаклап әйтсәк, туган тел бетү чигенә җиткәч, ата-бабай һөнәрләре юкка чыккач, татар милләте дигән “сөт”нең майлылыгы сизелерлек кимеде, аңа су кушылды. Димәк, гасырлар узган саен Ватаны югалган халыкның милли сыйфаты да начарая, ягъни чорлар үзгәреше аның бердәмлеген тарката, бөтенлеген ваклый. Димәк, “сөт”не ачымаслык итеп саклар өчен ахыр чиктә барыбер Туган ил кирәк!

Сәмигулла белән Хәернисаның кызы Энҗе бик тә акыллы бала, ә уллары юньсез булып чыгалар. Ни өчен?

Беренчедән, Энҗе чынлыкта Сәмигулла кызы түгел, аның тамырларында башка кан ага. Чын әтисе – Казаннан килгән коммунист, МТС директоры Әхмәтев.

Икенчедән, малайларның әти-әнисе көннәр буе эштә. Сәмигулла имән мичкә ясау заводында бондарь булып эшли, Хәерниса төзелештә сумала кайната. Аларның бала карарга вакытлары калмый. Сабыйларны Совет дәүләте тәрбияли: башта бакчада, аннары мәктәптә... Дәүләт ата-аналарның бала тәрбияләү вазыйфасын да алып бетерә, аларны йөк атлары сыман эшләтә.

Өченчедән, гаиләдә әти кеше үз урынында түгел. Улларын эшкә, мәсәлән, имән мичкә ясарга өйрәтми. Алар белән бергә уйнамый, шаярмый, мунчага

алып бармый. Һәр шимбә кичендә үзе генә мунчага китә, кайтышлый бер шешә алып кайтып кәефләнә һәм ятып йоклый.

Дүртенчедән, улларының арт сабагын укытырга кирәк чакта әниләре күрмәмешкә салыша, элекке татар гаиләсендә баланы куркытыр өчен еш кулланылган “атасы” дигән усал сүзне белми. Өйдә матчага кыстырылган сыек тал чыбыгы юк, шуның белән йомшак җирне сыдыручы ата юк. Хәзер гаиләдә яңа тәртипләр урнашкан, әби-бабай тәрбиясе онытылган.

Аның каравы, малайлар барысын да күреп үсәләр. Әтиләренә күз йоммыйлар. Тәмәке тартырга, аракы эчәргә өйрәнгәч, бозык юлга баскач, беркайда да озак эшли алмагач, аталарыннан көн саен хәмергә акча сорыйлар һәм аның шимбә өлешенә борын тыгалар. Өйдә тавыш чыгаралар, әтиләренә кул күтәрә башлыйлар, саклык кенәгәсен сорап бирмәгәч, аны кыйнап үтерәләр. Шул рәвешле, татар гаиләсендәге патриархаль тәртипне Совет хакимияте туздыргач, үсеп чыкты Сәмигулла малайлары.

Укучылар арасында яратылып укыла торган **моңсу бәян** (*лирик повесть*) XX йөзнең соңгы чирегендә татар прозачыларының (Фәнис Яруллин “Кыйгак, кыйгак каз кычкыра”, “Кайту”, Рахмай Хисмәтуллин “Оныкларым, сез бәхетлеме?”, Индус Сирматов “Керәшен кызы” һ.б.) игътибар үзәгендә булды. Әлеге жанрның мөһим үзенчәлеге – авторның тормыш материалын вакыйгалар эзлеклелегендә сөйләп чыгуы түгел, бәлки геройның эчке дөньясын, уй-хисләрен чагылдыруы. Бу очракта **моңсулык** (*лиризм*), кагыйдә буларак, фактның төгәллеге белән кушыла. Гадәттә мондый күренешне өлкән һәм урта буын язучылары әсәрләрендә күзәтергә мөмкин.

Моңсу бәянне үз иҗатында М.Мәһдиев уңышлы үстергән. “Торналар төшкән җирдә”, “Бәхилләшү”дә **моңлы сөйләү** (*исповедь*) рәвешендә бала һәм яшүсмер чагы узган туган авылы Гөберчәкнең гүзәл табигатен, авылдашларының күркәм холкын һәм игелекле гамәлләрен кабатланмас әдәби образларда чагылдырып, изге туган җиренә, анда гөрләп яшәүче искиткеч бай рухлы татар халкына кайнар мәхәббәтен белгерткән.

Мондый югары сәнгатьлелеккә автор ничек ирешкән соң? Әдип рухи җегәрне, илһамны, илаһи көчне, дәрт-дәрманны туган авылының тешеңне сындырылык салкын сулы Сафый чишмәсеннән, шәм кебек төз нарат-чыршыларның саф һавасыннан, каен җиләге исен иснәп һәм кыңгырау, сандугач тәпие, баллы куәт, алабай, дегет чәчәкләре чыгарган тымызык баллы һаваны сулап, бәрәкәтле җиреннән алган икән. М.Мәһдиев әтисе нигезенә – бертуган Равия апасы гомер иткән йортка – җиләк-җимеш мул өлгергән, алмагачлар алма кызарткан, үзе утырткан миләшләр пешә башлаган, бәрәңге сабаклары туклык исе тараткан вакытта, гомумән, табигать тулышып утырган

август аенда кайтырга ярата иде. Бу хакта ул болай язып калдырган: “Миңа да яшәү һәм иҗат итү өчен авылым суы, авылым һавасы кирәк. Шул авыл басуларының исе кирәк. Миңа көзен сентябрь кояшы астында моңсу камыл басуында тезелеп утырган салам эскертләре кирәк. Шул эскертләрнең баш әйләндергеч исе кирәк” [7; 250].

Туган җирне ярату дәрте язучының бөтен иҗатына сеңгән. Авылын сагыну хисе аңа иҗат итәргә илһам чыганагы булды. Автор “Торналар төшкән җирдә” әсәренә урта гасырлар татар шагыйре Әбелмәних Каргалыйның “Туган җирне сагыну дәрте бервакытта да бетми икән...” [9; 7] дигән мәгънәле сүзләрен эпиграф итеп алып, үзенең саф хисләрен дә ассызыклаган, повестен дә шул пакъ кичерешләре белән сугарган: “...1976 елның октябрендә мин Франциянең Париж, Марсель, Авиньон шәһәрләрендә йөрдем. Үзебезнең авылдан ерак, бик ерак идем мин. Эйфель башнясы янында басып торганда, Урта диңгезнең “Иф” крепосте урнашкан таш утравына катерда чыкканда яки Роден музеендә йөргәндә кая инде үз авылыңны уйлап тору, искә төшерү? Баш әйләнгән, тәэсирләр шундый көчле, ниндидер бер мизгелдә үзеңне онытып, югалып торасың. Ләкин нәкъ шул хәлдә – табигыйлекне югалткан бер хәлдә – нигәдер минем йөрәгем сулыгып-сулыгып алды һәм, Сан-Мартин бульварындагы затлы ресторанның купшы савыт-сабасын бер читкә этеп куеп, туп-туры үзебезнең авылга кайтасы һәм минем хәтергә килгән кешеләр белән капка төбендә рәхәтләнеп бер сөйләшәсе килде. Мин моны – бу теләкне – берәүгә дә әйтмәдем, әйтсәм, моны йә кыланчыклык, йә бик нык чикләнгәнлек дип кабул итәрләр иде, әмма бу әсәрем шунда языла башлады дип әйтә алам.

Хәзер сәбәбен дә беләм. Зур бульварларда йөргәндә, затлы рестораннарда ашап-эчеп утырганда, миемне өзлексез бер фикер тукып торды: боларның күп нәрсәсе безнең белән уртак лабаса...” [9; 7].

Язучы гаять кызыклы күзәтүе белән үзе һәм гади укучы өчен ачыш ясаган. Баксаң, 70 елларда французлар утызынчы-кырыгынчы елларда яшәгән татарлар кебек киенгән, ашаган икән: *киндер ыштан* (джинсы), безнең авылда *“күтүмкә”* дигән *киндер капчык* яки *“арыш капчыгы”* (джинсовая сумка), *киндер күлмәк* (холщовая рубаха), *киндер алъяпкыч* (холщовой фартук), *кызылга, акка, карага “каккан”, манган кайры тун* (красная, белая, чёрная дублёнка), *ат ите* (конина), *сагыз* (жвачка), *бурабзар* (бурап эшләнгән абзар), урындык урынына *нарат, юкә, имән, каен бүкәне,* өстәл урынына *агач төбе* (пень), *кургаш таба* (свинцовая сковорода), *катык...*

“...Урам тулы халык: яше, карты-карчыгы, кызы-егете, французы-негры – барысы да джинсыга төренгәннәр. Киндер, безнең авылда гасырлар буе үстерелеп, тукылып, эрләнеп сугылган киндер” [9; 7-8].

Хәзерге россия җәмгыяте дә безнең ата-бабайлар киеп узганга – киндер ыштан, киндер күлмәккә яңадан әйләнеп кайтты. Безгә бит аны җитмешенче-сиксәненче елларда онытырырга тырышып яттылар.

Шулай итеп, дөнья халыклары көнкүрештә үзара рухи якынлык һәм матди бәйләнеш кичерәләр. Күргәннәреннән чыгып, автор мондый нәтиҗәгә килгән: “Димәк, дөньядагы бөтен халыклар белән уртак гадәтләребез, уртак гамәлләребез бар безнең. Димәк, туганда ук бөтен холык-фигылебез, эш-гамәлләребез аркылы бөтендөнья халыкларына бәйләнеп туганбыз без” [9; 13].

Аның геройлары дөреслек, миһербанлылык, намуслылык кебек гуманистик кыйммәтләрне үзләренә сеңдергән мөстәкыйль характерлар булып формалашкан. Хәдичәттәй, Камиләтти, Кәшифәтти, Камәртти, безнең авылда акушерлык хезмәтен башкарган Газзәтти белән Гайшәтти (әтиемнең кендек әбисе иде), Наһар түти, Мәрфугатти, Маһиҗамал түти (авылда аны Майҗамал тәтә дип йөрткәннәр), Бибинурттә, Миңлебикәтти, Мәстүрә (безнең авылда нигәдер Мәчтүрә, күршем иде), Зөлкамал, Гыйльменисаның прототиплары – Гөберчәктә гомер иткән акъяулыклы әбиләр, реаль шәхесләр.

Мәһдиев “Торналар төшкән җирдә” повестенең “Кереш сүз”ен болай башлаган: “...Безнең авылдан бер генә герой да, бер генә космонавт та, бер генә академик та чыкмаган. Гап-гади, иң гадәти бер авыл. Анда зур сулар, таулар, иркен болыннар юк, кыялар юк. Тагын бик күп нәрсә юк. Бөтен булган байлыгы – урман, чишмәләр һәм кешеләр. Мин менә шулар турында сөйләргә телим” [9; 7].

Кыскасы, аның бу әсәре “безнең авылда яшәгән, бүгенге буынга юньле әхлак-гадәтләр тапшырып дөньядан киткән кешеләр турында...” [9; 13].

Гомумән, язучы әнә шул йөзьяшәр акъәбиләр – халыкның сөекле ул-кызлары – хакында диңгез күк киң хатирәләрен күңеле түрендә саклап йөрткән һәм җан җылысын салган, киләчәк буыннар өчен түкми-чәчми теркәп калдырган. Сүзләрдән энҗеләр тезүе – Мәһдиев каләменең иң сәләтле, иң затлы үзенчәлеге, татар халык җырында җырланганча:

“Энҗе кебек теш араңнан
Сайланып чыга сүзең...”

Әдәби сүз ярдәмендә әдип 30-50 еллар татар авылының җанлы манзарасын тудырган. Шул әбиләр безнең авылның яшәеш фәлсәфәсен тәшкил иткәннәр, халкыбызның гасырлар дәвамында чарланган гореф-

гадәтләрен онытмаганнар, кешеләрне табибка караганда шәбрәк дәвалаганнар. Майҗамал түти күрше-күләннең тайган буыннарын урынына утырткан, сынган сөякләрен төзәткән. Автор аны авыл “докторы” дип атаган.

Һәрберсенең үз белгечлеге бар, һәркайсы – үз эшенең остасы: “Майҗамалттә “ортопед” булса, безнең күрше Бибинур түти (аны да Бибинурттә дип кенә йөртәләр иде) “киң профильле белгеч” иде. Моның һөнәре: сыер бозаулату, кайчы-пычак белән эш итү, үлән, чәчәк, бал, яфрак белән дәвалау иде” [9; 84].

Шул рәвешле, повестьтә сурәтләнгән акъяулыклы әбиләр халык медицинасын үзләштереп, авылдашларын физик яктан да, рухи яктан да шифалаганнар. Авылның сәләмәт хәлләтен үзләренең “дәвалау-савыктыру методикасы” нигезендә тотып торганнар.

“...Мәрфугатти – урман карчыгы иде. Ул җәй буе урманда була иде. Кешеләр җиләккә кояш чыгып көянтә буе күтәрелгәч китәләр, Мәрфугатти исә Кояш чыкканчы кызу-кызу атлап китеп бара һәм төш җиткәнче зур су чиләген мөлдерәтеп кура җиләге алып кайта иде. Ата-аналар балаларын аңа ияртеп җибәрергә тырышалар һәм кичтән белешеп тә куялар иде” [9; 87].

Авыл карчыклары үзләрен тышкы дөньядан аерылгысыз итеп сизгәннәр һәм табигать балалары итеп кабул иткәннәр. Бу хәләт исә аларның җанына кечкенәдән үк уй-хыял сафлыгын, игелек кылырга әзер булу теләген сеңдергән. Мәрфугатти балаларны җиләк җыярга, җыйган чакта бер җиләк тә капмаска, савытын тутыргач, әниләре өчен кура җиләген сабагы белән җыярга, аннары гына җиләктән авыз итәргә, ягъни сабырлыкка, хезмәт сөяргә өйрәткән. Бу күренеш утызынчы-илленче еллар татар авылында буыннар арасындагы дәвамлылыкның яшәүчәнлеге турында сөйли, димәк, әле ул чакта гадәтләр нык булган. Димәк, әсәр геройларының көн дә күргән тирәлек матурлыгыннан – авыл табигате гармониясеннән – башка шәхес булып өлгерүләре һич мөмкин түгел.

Хәдичәтти, Мәрфугатти гомер буе кешеләргә, балаларга игелек күрсәтеп яшәгәннәр. Хәдичәттәйгә 1941-1942 елларда ике улының да хәбәрсез югалуы турында кайгы кәгазе килгән, ләкин яхшылыклары өчен Аллаһы Тәгалә анага мәрхәмәтлелек күрсәткән: сугыш беткәч, аның уллары исән-сау туган йортка кайтып төшкәннәр. Хәдичәтти нәниләрне бик яраткан, сабыйлар телендә артистланып сөйләшә белгән, нарасыйларны яшел чирәмле ишегалдына чакырып катык белән сыйлаган. Өстәвенә, ул яшь вакытта җырларга яраткан, 80 яшьлек карчык көр тавыш белән аспирант Мәһдиевкә Габделҗаббар Кандалый шигырен җырлап та күрсәткән:

“Әя агач, яшең күпме?

Түгелгән яфрагың күкме?
Минем күк хәсрәтең күпме?
Диеп сорыйм агачлардан...” [9; 91]

Хәдичәтти җыйган китаплар арасыннан аспирант Мәһдиев “Йосыф кыйсса”сының яңа бер кулъязмасын табып алган. Бу нөсхә хәзер Казан университетының Н.И.Лобачевский исемендәге гыйльми китапханәсендә сирәк кулъязмалар бүлегендә саклана һәм шул вариант поэманы өйрәнгән галим Фазыл Фасеевнең фәнни хезмәтендә телгә алынган. Хәдичәттинең исеме татар әдәбияты тарихына лаеклы рәвештә кереп калган [9; 92].

Мәрфугатти – дару үләннәре буенча белгеч: җәен җыеп киптергән каен һәм кура җиләген, шомырт, гөләп җимешен (шиповник), бөтнек, валериан, кура яфракларын салкын кыш көннәрендә суык тигән авылдашларына өләшкән һәм шул үләннәрнең шифалы төнәтмәсен эчкәч, ни гаҗәп, бик тиз сихәтләнгәннәр.

Мәһдиев һәр персонажын әхлак бизмәненә салып, аларның тирәлеккә, кеше яшәешенең якты башлангычларына мөнәсәбәтен ача. Автор гади кешеләрнең җыр-моң аша авырлыкларны җиңүен, ихласлык, гаделлек кебек бөек сыйфатларын тасвирлый. Боларга ул урынлы лирик чигенешләр, уңышлы композицион алымнар, оста тотып алынган сәнгатьлелек детальләре, ачык бәяләмәләр ярдәмендә ирешә.

Сурәтләнгән күренешләрнең объективлыгына, эпик колачына омтылуга карамастан, язучы укучы игътибарын геройларының моңсу хис дөньясына җәлеп итәргә тели. Повестьнең уңышы – һәр каһарманга карата рухи таләпчәнлек белән моңсулыкның бергә кушылып китүендә.

Моңсулык, гомумән, М.Мәһдиев әсәрләренә хас төп билгеләрнең берсе. Аның повестьләреннән ана телемнең аһәңе, халкымның моңы, йомшак һәм моңсу юморы күңелгә язгы ташкындай агыла да агыла. Җаныңның әллә кай төшләре актарылып сыкрый, сызлый, йөрәгең хисләр өермәсе белән тулып, салкын сулы саф чишмәдәй, ташый башлый. Мәһдиев каләменең сихри көче сине Казан артына, Гөберчәккә алып кайта, бәбкә үләнле урамнарында йөртә, таллыклы су буйларына алып төшә, Сафый, Гали чишмәләренең тешеңне сындырырдай салкын суын эчертә, Гөберчәк урманының җиләкле аланнарына алып бара, чүннек артында, ике нарат арасында кызарып пешкән бармак башы хәтле каен-кура җиләгеннән, чем кара эре шомырттан, өлгергән чикләвектән авыз иттерә, кайтышлый Масра басуына төшкән торналарны күрсәтергә чакыра һәм син торналар төшкән җирдә Мөхәммәт Мәһдиевнең үзе белән очрашкандай буласың, күңелеңне шашкын хис биләп ала, бугазыңа төер утыра, күз төпләрең ачы күз яшьләреннән дымлана, эчтән генә әдипнең

моңсу сүзләрен кабатлыйсың һәм иреннәрең ирексездән акрын гына пышылдыйлар: “...Масра басуы тын, бик тын. Шундый тын, дөньяның зыңлаган тавышы ишетелә, дөнья сабырлык, акыл чәчә, кызыл шар инде күмелеп бара, җир әйләнә, ә мин шушы мәһабәт тынлык уртасында, торналар төшкән җирдә берүзем басып торам.

Бу – минем туган җирем...” [9; 232].

М.Мәһдиев реалистик яссылыкта геройларының дөньяга карашын, рух байлыгын һәм газиз туган җиргә мәхәббәтен чагылдыруы белән “Торналар төшкән җирдә” әсәрен классик татар лирик повестьләре рәтенә куйды.

Мәгълүм ки, безнең әдәбият элек-электән авыл темасын киң яктыртты. Халык язмышының, иҗтимагый тормышның барометры саналган повесть жанры 80-90 еллар татар прозасында авыл кешесен игътибар үзәгенә алды.

XX гасырның соңгы чирегендә язылган повестьләрнең күбесе – А.Гыйләҗев “Җомга көн, кич белән...”, “Әтәч менгән читәнгә...”, В.Нуруллин “Җавап бир, кеше!”, Р.Мөхәммәдиев “Истәлек өчен – Гыйлемханга...”, “Ак кыялар турында хыял”, М.Галиев “Нигез” һ.б. – авыл темасын үзәккә алган әсәрләр әдәбиятыбыз тарихына татар повесте үсешендәге мөһим бер этап буларак кереп калды.

Рус әдипләреннән Василий Шукшин (“Ана йөрәге”, “Көзен”, “Кояш, карт һәм кыз”, “Якташлар”), Валентин Распутин (“Янгын”), Виктор Астафьев (“Кайгылы детектив”) *урыс авылы бетә* дип беренче булып чаң кага башлыйлар. Авыл темасын яктыртуда зур тәҗрибә туплап өлгерәләр.

Тора-бара татар язучылары да авыл хуҗалыгы реформасының чын асылына төшенәләр. Безнең повестьләрдә хезмәт кешесенең фикерләү рәвешенә, катлаулы кичерешләре дөньясына үтеп керү ысуллары төрләнде. Әдипләрне үзгәрешләрнең икътисадый эффекты һәм уңыш алудагы рентабельлек түгел, ә фәлсәфи-әхлакый юнәлеше кызыксындыра. Авылга әхлак ноктасыннан бәя бирү омтылышы повестьләрдә көчәеп китә. Әхлак тәрбиясе мәсьәләсе беренче планга чыга. Сүз осталарын шәхеснең җәмгыять һәм коллектив каршында җаваплылыгы, дәүләтнең гуманлылыгы, матди-рухи байлыкларның үзара бәйләнеше, гуманизм идеяләре, крестьянның җиргә мөнәсәбәте кебек проблемалар ныграк борчый башлый.

Әйтик, җәмгыять алдында кешенең җаваплылык хисе кимү язучылардан әхлак традицияләренең чыганагын эзләүне таләп итә һәм алар өлкән буын язмышын өйрәнергә тотыналар. Нәтиҗәдә буыннар арадашлыгы, дәвамчанлыгы яңа эчтәлек белән байый, мәсәлән, М.Мәһдиев сугышка кадәр, сугыш елларындагы һәм аннан соңгы чордагы авыл, колхоз тормышын кайта-кайта тасвирлый. Болай сурәтләү нигезендә шулай ук юньле әхлак-гадәтләрне

эзләү ята. Автор фикеренчә, сугышка хәтле авыл кешеләренә әхлакый югарылык, ярдәмчеллек, өмәләрдә күмәкләшеп, бушлай эшләү гадәте хас, алар табигатькә якынрак булганнар, Җир-Анага хөрмәт белән карап, Аллаһка шөкер итеп яши белгәннәр. Мондый күркәм хасиятләрне язучы аеруча матур итеп чагылдырган. Әдип ул чакта кешеләрнең шатлык-сөенечләре, борчу-кайгылары уртак булуы турында яза: “1941 елның җәй башында авылда клуб төзергә керештеләр. Тиз эшләделәр – иллеләп балта остасы бар иде. Алар арасында үзенең беркемгә дә тоттырмый саклаган җыйнак үткен балтасы, кулүяулыгына төргән кадерле алмазы белән Шәйхи дә бар иде.

Менә беркөнне авыл Советы урнашкан Сикертән авылыннан чапкын килде: сугыш... Ирләр балталарын бүрәнәгә кададылар да дәшми-тынмый тәмәке төрделәр, һәркемнең эченнән ут чыккан сыман булды” [9; 148].

Ил өстенә килгән бәла-казаны сыкрамыйча үз җилкәләрендә күтәргән авыл кешеләренә бердәмлек, бер-берсенең ярдәмен тою һ.б.ш. сыйфатлар авыр сугыш елларын җиңеп чыгарга булышкан. Мәһдиев өлкән буыннан рухи матурлык эзли һәм таба. Бүгенге авыл кешесендә исә шул күркәм хасиятләр югалган, ул – **рухи фәкыйрь** дигән куркыныч диагноз куя автор. Һәм өлкәннәр тәҗрибәсен яшь буынга тапшыру максатыннан әдип үзе яхшы белгән 30-50 еллар авылына как-кат мөрәҗәгать итә.

Минемчә, шул чор татар халкының тормышын, күңел дөньясын, иманын, милләт буларак яшәү рәвешен аңардан да әйбәт белгән, бөтен нечкәлекләренә кадәр аңлап сурәтләгән язучы хәзерге әдәбиятта юк. Мөхәммәт Мәһдиев Гөберчәкне беренче чиратта “Торналар төшкән җирдә” әсәре белән бөтен республикага танытты. Әгәр шулай әйтергә яраса, бу повесть – безнең авылның энциклопедиясе! Татарстанның халык язучысы Гариф Ахунов сүзләре белән әйтсәк: “Ул үзе дөньяга килгән Гөберчәк авылын, кешеләрен легендага әйләндерде. Ул үзен авыл җырчысы, авылның пәйгамбәре итеп танытты” [3; 19].

## Кулланылган әдәбият

1. Дәрдмәнд (Закир Рәмиев). Исә җилләр: шигырьләр. К.: Тат. кит. нәшр., 1980.

2. Проблемаларның үзәгендә – кеше. Әдәбиятта яңалык тойгысы // Казан утлары. – 1981. № 10. – 147 б.

3. Кеше китә – җыры кала: повестьләр, истәлекләр, хатлар / Төз.-ред. Л.Якупова. К.: Татар китабы, 1996. 273 б.

4. Миңнуллин Ф. Затлылык: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. К.: Тат. кит. нәшр., 1989. 144 б.

5. Галиуллин Т. Дәвамлылык: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. К.: Тат. кит. нәшр., 1987. 168 б.

6. Яхин А. Әсәргә ничек анализ ясарга? // Мәгариф. – 2000. – № 2. – 21 б.

7. Мәһдиев М. Сайланма әсәрләр: 3 томда. III т.: повестьләр, роман. К.: Татар. кит. нәшр., 1996. 576 б.

8. Дәрдемәнд. Агарган кыл: шигырьләр. К.: Мәгариф, 1999.

9. Мәһдиев М. Сайланма әсәрләр: 5 томда / Төз. Г.Хәсәнова. III т.: повесть, роман. К.: Татар. кит. нәшр., 2009. 480 б.

## IV бүлек. Көлә белеп көлә иде

(*М.Мәһдиев әсәрләрендә юмор*)

Исемнәре үлемсез шәхесләр була. Үзләре бу якты дөньядан китсәләр дә, әсәрләре, моңлы бер җыр кебек, халык күңелендә яши. Шундыйларның берсе – Татарстанның халык язучысы, Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе, үткен каләмле тәнкыйтьче һәм күренекле әдәбият галиме Мөхәммәт Сөнгатулла улы Мәһдиев. Әдип арабыздан вакытсыз китте. Ләкин безгә ядкәр булып аның кабатланмас мирасы – уналты китабы, гыйльми хезмәтләре һәм публицистик мәкаләләре калды.

Аны язучы итеп таныткан “Без – кырык беренче ел балалары” исемле тәүге повесте белән соңгы әсәре – “Ачы тәҗрибә” истәлекләр китабын янәшә куеп, чагыштырып тикшерену әдипнең юмористик фикерләве үсешен күзәтергә мөмкинлек тудыра.

Без бу мәкаләдә М.Мәһдиев әсәрләренең юмор үзенчәлекләреннән иң сыналганнарын гына карап үтәрбез. Аның прозасында мондый көлкеле алымнар бик күп. “Без – кырык беренче ел балалары”нда рәсем укытучысы укучылары тарафыннан көлү объектына әйләнә: **“Әтисе потомственный дворянин булган икән. Моны ишетүгә, безнең колаклар торды. Әлтафи һич тә риза булмыйча, бөтен класска ишетерлек итеп татарча:**

**– Череп таркалган сыйныф, – диде.**

**Әркәшә дә моңа кушылып:**

**– Алайса, безде алпавыт калдыгы укыта икәд, – дип куйды”.**

Беренче әсәре белән чагыштырсак, “Ачы тәҗрибә”дә әдипнең каләме тагын да үткен: фикере кыю, сүзе зәһәр. Сатирик метафора алымын кулланып, автор үткәндәге гаделсезлекләрне усал тәнкыйтьли: **“Дәүләт иминлегенең утызынчы-кырыгынчы еллардагы хезмәткәрләренә – XX гасыр каннибалларына – нәләтем”.**

М.Мәһдиевкә чагыштыру алымы белән ясалган юмор стиле хас. Чагыштырулар аның сөйләменә җанлылык, эмоциональлек бирә, автор хикәяләвенә төрле сурәтле төсмерләр өсти.

*Кебек*, *шикелле*, *сыман* бәйлекләре, -*дай*, -*дәй* ясалма рәвеш кушымчалары белән тудырылган чагыштыруларга әлеге ике әсәрдән кайбер мисаллар: **“Гыйззәтуллин питон авызына үз ихтыяры белән кереп барган *гипнозланган куян шикелле* берни аңламыйча аның артыннан кабатлый”.**

Биредә әдәби герой, гипнозланган куян белән чагыштырылып, көлке хәленә куела.

“Ачы тәҗрибә”дән: **“...без – егетләр, бәбкәләрен тилгәннән саклаган *ата каз кебек* авыл егетләреннән кызларыбызны сакладык, шулай да бер “хитрие” башта безнең егетләр белән дуслашып алды да Эльвира исемле кызыбызга ияреп кайтты”.**

**“Шуның өстенә укытучысы – нечкә аяклы, чандыр яңаклы, *шүрәле бармагыдай* нәзек озын бармаклы ир уртасы бер кеше”.** (“Без – кырык беренче ел балалары”.)

Ике әсәрне янәшә куеп караганда “Ачы тәҗрибә”дә чагыштырулар күбрәк, төрлерәк.

М.Мәһдиев прозасында комик гиперболага да мисаллар күп: **“Егетләрнең берсе аеруча таза, анысы Фәрит исемле иде, ул көненә дүрт-биш кило сыер ите ашап шул дәрәҗәдә тазарды ки, башын борганда арка – җилкә белән тоташтан борыла иде”.** (“Ачы тәҗрибә”.)

Биредә сүз – зур аппетитлы язучы Фәрит Гыйльми турында.

“Без – кырык беренче ел балалары”нда арттыру алымы көлү эффектын көчәйтә: **“Гренландия бик зур җир кисәге, – дип алып китте ул. – Андый зур җир кисәге бик сирәк очрый. Анда бик суык, анда аюлар, жирафлар, кыр кәҗәләре һәм моржлар яши... Гренландиядә хуш исле тәмәке үстерелә”.**

Шулай да истәлекләр китабында авторның көлке арттыру алымы белән иркен эш итүен әйтеп үтәргә кирәк. Шәхеснең нинди эш яратуына, шуңа төп игътибар бирүенә нигезләп, Мәһдиев үзенең юмор стилен тудыра: **“Гәзитләргә чумдым. Һәрберсенең беренче битендә көләч йөзле Никита Сергеевич. Йә кукуруз чәкәнен иснәп тора, йә дуңгыз баласын кочаклаган”.**

М.Мәһдиев комик литотага да мөрәҗәгать итә. Беренче әсәрендә булмаса да, “Ачы тәҗрибә”дән мисал табарга мөмкин: **“Иптәш Сталин әнә әйткән бит адмирал Кузнецовка:**

**– Балтика ул нәрсә? Ул – бака күле, – дигән”.**

М.Мәһдиев сурәтләгән портретларның холкы (характеры) көлкеле. Аларны шушы әсәрләр нигезендә берничә төргә бүләргә мөмкин:

1. **“Кайсыдыр чоланнанмы, тәрәзә артыннанмы, зең-зең тавыш яңгырый, белеп торабыз инде – Марсель Галиев. Актаныш культура бүлегендә эшләгән бер кечкенә гәүдәле егеткә кичтән кадалган иде. Үрмәкүч белән чебен бәрелешкәндә көрәш ничек тыгыз, киеренке булса, монда да шулайрак иде. Болай гына аерылу юк. Юк, вәссәлам. Шаярма син, М.Галиев булган җирдә андый скандалсыз була алмый. Татарга да бер Ноздрев кирәк...”** (“Ачы тәҗрибә”.)

Монда М.Мәһдиев каләмдәш дустыннан дусларча көлә, җиңел юмор белән елмая.

2. Тарихи шәхесләрнең көлкеле портретларын сурәтләгәндә ул усал, теле үткен:

**“Рәхмәтләр төшсен Ленинга –**
**Ике сыер саудырды.**
**Ләгънәт төшсен Сталинга –**
**Бер кәҗәгә калдырды”.** (“Ачы тәҗрибә”.)

Биредә янәшә кую алымы кулланылып, Ленин мактала, ә Сталин сүгелә, сатира белән фаш ителә.

**“Мәйданның бер ягында – КАИ башында көләч елмайган Ильич портреты, биеклеге ун метрлар гына булыр, күкрәгендә кызыл бантик.**

**“Верной дорогой идете, товарищи!” дип елмая. Аннан портретлар: иң шәбе икенче, яңа Ильич, ул вакытта әле маршал түгел, алтын йолдызлар да әле бишәү үк түгел. Аннан Косыгин, Микоян, һәркайсының күкрәгендә бер дә, ике дә йолдыз. Вәт геройлар, әй”.** (“Ачы тәҗрибә”.)

Мисалдан күренгәнчә, тарихи шәхесләрнең портретлары бүген дә елмаю тудыра. Әйтергә кирәк, мондый портретлар фәкать “Ачы тәҗрибә” әсәрендә тупланган.

3. Әдәби геройларның көлкеле портретлары, киресенчә, соңгысында очрамый. “Без – кырык беренче ел балалары”нда исә алар шактый күп: **“Гыйззәтуллин теге коры яшен чатнаган вакытта авызын ачып калган иде, берничә секунд буена шуны яба алмыйча катып торды. Бите ап-ак булды. Ләкин сары күлмәкле – нигездә мәрхәмәтле кеше. Ул, Гыйззәтуллинның битенә кызыл таплар чыккач кына, яңадан дәште”.**

М.Мәһдиев юмористик төсмерле сүзләрне аеруча яратып куллана. Бу – әсәрләренең юмор белән сугарылганлыгына тагын бер дәлил. Кайбер үзенчәлекләргә тукталыйк: мисаллар мемуар жанрында язылган әсәрдә күбрәк.

а) Рус сүзләренең бозылып бирелеше көлке тудыра:

**“Мин торып йөгердем, бер хат, берничә газета алып килдем, шакып бүлмәсенә кердем дә, русча ярып, аңа:**

- **Халим Фаттахович, вот, *принесел,* – дидем.**

**Өлкән укытучы буыла-буыла, йөткерә-йөткерә көлде”.** (“Ачы тәҗрибә”.)

б) М.Мәһдиев каләмдәш дуслары, остазлары турында җылы юмор белән яза. Җиңелчә юмор аша татар акцентының үрнәген бирә: Ул М.Гайнуллин сөйләмендә чагыла: **“Яуа работа нисомнинны заслуживает присуаения яму искомой эстипени кандидата филалагических наyык.**

**Молодец, рәхмәт, Мөхәммәт ага. Синең русчаңнан яратып кына көләләр, Рәсүл Гамзатовларны андый акцент бизи генә әле...”** (“Ачы тәҗрибә”.)

в) М.Мәһдиевкә шәхеснең гадәт-холкын җиңел юмор аша ачу хас. Мәсәлән:

**“– Исәнмесез, Гази абый, Сездә йомышым бар иде...**

**Тирләгән, бүреген салган, кайнар кулын биреп күрешә.**

**– Тыңлыйм, пожалуйста.**

**– Гази абый, ни бит. Менә бер мәкалә язган идем журналга, берәр өлкән галимнән рецензия кирәк, диделәр.**

**– Ярый, бик яхшы, мин уңай рецензия язып бирермен.**

**Син телсез каласың: темасын, кайсы журнал икәнен сорамады – уңайны язам, ди.**

**– Ну бит, Гази абый, Сез әле...**

**– Ә, Син язгач яхшы мәкалә булачагына шигем юк минем. Сал минем портфельгә, кайчанга кирәк?..”** (“Ачы тәҗрибә”.)

Көлү төсмерле сүзләр бигрәк тә “Без – кырык беренче ел балалары”ндагы геройлар сөйләмендә киң чагылыш таба.

г) Аерым сүзләргә басым ясау: **“Ах, бу “гаять”не! Ну язалар инде китап авторлары да, ач калгырлары!”**

д) Сүзләрне охшатып язу: **“Без тынып калдык. Мөрәле малае Әлтафи миңа борылып пышылдап кына болай диде:**

**“– Чукынды, малай, монда *ат печүчеләр* әзерлиләр икән, *укытучылар* түгел”.**

е) Эш яки хәл: **“Зоология укытучысы, куенына кереп, озак кына актарынды да чынаяк зурлыгындагы сәгатен тартып чыгарган булды. Әлтафи артка борылып елмаеп куйды. Узган төн генә йокы алдыннан Әлтафи сөйләнеп яткан иде: имеш, зоология укытучысына корчаңгы йоккан, шуңа күрә дәрес вакытында сәгать караган булып бер кашынып ала икән”.**

Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗев әйткәнчә, “Мәһдиев ни хакында, кем хакында гына язмасын, ул дөньяның иң каршылыклы вакыйгаларына да моңсу, йомшак юмор, якты күз белән карады. Мәһдиевтәге моңсу, җиңел юмор сирәк очрый торган табигать бүләге ул”. [1]

## Кулланылган әдәбият

1. Гыйләҗев А. Сайланып чыккан сүзләр... // Кеше китә – җыры кала: Повестьләр, истәлекләр. – К.: “Татар китабы” нәшр., 1996. – Б. 23.

## V бүлек. М.Мәһдиевнең публицистик осталыгы

М.Мәһдиевнең күпсанлы әдәби-публицистик мәкаләләрендә, эссе-очеркларында үз милләтен чын күңелдән яратуы, ихластан горурлануы, шул ук вакытта аның ачы язмышына көенүе һәм яхшы нияттән тәнкыйтьләп, халкыбызны тарихи асылына кайтару омтылышы чагыла. Мәһдиев публицистикасы тирәнтен һәм әтрафлы тикшеренүне күптән көтеп ята, чөнки талант – үзе бер дөнья, татар халкының милли байлыгы, "табигатьнең могҗизаи бүләге, мәдәниятнең нигезе һәм илнең горурлыгы" [1; с. 33].

М.Мәһдиевнең иҗат лабораториясен өйрәнүче әдәбият белгече Рәшит Фәтхерахманов әдипнең нык рухлы, уникаль психологик сәләткә ия булуын искәртә [2].

"Мәшәкатьле һөнәр" мәкаләсендә [3] М.Мәһдиев болай язган: "Мин педагогика фәненең иң әһәмиятле бер законын олыгайган саен тирәнрәк аңлый барам. Кешене формалаштыруда өч шарт бар, ди ул фән. Болар – нәселдән килгән сыйфатлар, тирәлек һәм тәрбия. Зур ачыш бу!"

Ул язучылык өлкәсендә дә нәтиҗәле эшләгән, публицистика жанрларында да актив иҗат иткән. "Өендә гел язып кына утырган язучы минем хәтле язмый. Минем бигрәк тә соңгы елларда газета-журналларда елына 80-88-90 мәкаләм чыгып барган. Ул кадәр күләмдә сирәк журналист яза. Шулай итеп, 65 елда бер журналист гомерен кичергәнмен. Без белгән күп кенә кешеләр бернинди фәнне эшләмичә, бернинди әсәр язмыйча бер доцент гомерен кичерделәр. Өчесен бергә кушсаң, 195 ел килеп чыга... Шулардан тора минем гомерем" [4].

Милләттәшләрне нык кызыксындырган мөһим темалар, дәүләт игътибарын сораган әһәмиятле проблемалар М.Мәһдиевне публицистика йөген тартырга мәҗбүр иткән, ә публицистка *авыр миссия* йөкләнгән. "Без публицистларның даими эшен эшләргә – заман тарихын язарга тиеш..." [5; с. 1].

Үз геройлары алдында икейөзләнүче, тар фикерләүче, әзер журналистик калыплар кулланучы иҗат әһеленнән яки кайбер "озын сакаллы", ләкин "кыска акыллы" редакторлар көен көйләүче һәм алардан куркып торучы журналисттан һичкайчан яхшы публицист чыкмый. М.Мәһдиев исә чын халыкчан публицист иде. Ул вакчыл бәндәләр белән вакланмаган, түрәләр

каршында ялагайланып, тәлинкә тотып үз дәрәҗәсен төшермәгән, рәнҗетүчеләргә рәнҗешен белгертмәгән.

Узган гасырның 80 еллары ахырында, үзгәртеп кору сәясәте нәтиҗәсендә, татар халкы тирән “йокы”дан акрынлап уянды: бөек тарихы белән кызыксына башлады, тарихи хәтере хәрәкәткә килде, милли үзаңы терелде, шанлы үткәне, данлы бүгенгесе һәм якты киләчәге өчен олы горурлык хисе ташып чыкты. Татар матбугатын даими укып баручы, киң фикерле белүче кайбер милләттәшләребез тарих һәм әдәбият галимнәренә, шул исәптән М.Мәһдиевкә дә, үзләрен бик кызыксындырган сораулар юлладылар.

“Казан арты авылларының исемнәре каян килеп чыгуын сорап, соңгы елларда миңа да хатлар язалар. Мин бу өлкәдә белгеч түгел, бу мәсьәлә белән махсус шөгыльләнгәнем юк. Фән-гыйлем өлкәсендә минем егерменче гасыр башы татар әдәбиятына һәм халык иҗатына караган *азмы-күпме* (курсив безнеке. – И.Ф.) хезмәтләрем бар” [6], – дип башлап киткән ул, тыйнаклык саклап.

Минемчә, Казан арты, Арча төбәге авыллары тарихын М.Мәһдиев кадәр белгән язучыны бөтен Татарстан буйлап эзләсәң дә, табалмассың.

“Туган як авазы” мәкаләсендә Казан артына урнашкан татар авыллары исемнәренең тарихын яктырткан: аларның килеп чыгышын өйрәнгән, кызыклы күзәтүләре, гыйбрәтле мисаллары белән уртаклашкан, авыл исемнәребез тарихы дигән буталчыклы өлкәгә үзеннән күпмедер гыйльми өлеш керткән. “Бер авылның да исеме очраклы тумаган, моны аксиома буларак кабул итәргә кирәк”, – дигән ул.

Галим ике фәнни концепциягә нигезләнгән:

“1. Авыл исемнәре шул тирәдәге урман, елга, басу, шунда үскән агач, шул тирәдәге рельефка һәм шунда тереклек иткән кыргый хайваннар, кошларга бәйле рәвештә ясалган.

2. Казан ханлыгы рус дәүләтенә кушылганнан соң (*кушканнан соң дип укыгыз. – И.Ф.*) кайбер авыллар рус түрәләре, землемерлар тарафыннан исәпкә алынган һәм кәгазьгә язганда рус теленә якынайтып үзгәреш кичергән, димәк, кайбер авылларның исемен русчадан татарчага таба чыгып эзләргә кирәк”.

Бу концепцияләргә таянып, мондый нәтиҗәләр ясаган:

а) Күп кенә авылларның исеменә “ил” сүзе нигез булган, мәсәлән: Торна иле, Ку иле, Мари иле;

б) “Ор” сүзе бер урында калкулыкны, икенче урында чокырны, өченче урында коры елганы аңлаткан, мәсәлән: “Ку орысы”, “ор” сүзе Арча исеменең тамырында да ята;

в) “Казан арты авыллары рәсми документларда берничә тапкыр исемнәрен үзгәрткәннәр. Моңа йә алпавыт җирбиләүчелеге, йә патша администрациясенең кайбер җир-оештыру чаралары, кайвакытта сыйнфый көрәш моментлары тәэсир иткән”. Мәсәлән: Арча районының *Гөберчәк* авылы 1930 елларда *Кече Му* дип аталган; *Сеҗе* авылы – өстәмә исеме *Мурья Мусич*; *Казанбаш* авылы – төп исеме *Кармыш*; аның янындагы “*Четыре двора*” дигән күрше урыс авылы татарчалаштырылып *Өстеял* дип атала, чөнки анда *Постоялый двор* булган, шул сүзтезмәдән тәрҗемә кылынган; *Александровка* авылы (татар телендә – *Тыңламас* исемле).

Арча төбәгендә туып үскәнгә күрә, бездә соңгысы хакында өстәмә мәгълүмат бар. Бу авылның беренчел исеме – *Талнамаз*, элек ул татар авылы булган. Инеш буенда таллар күп үскән һәм анда халык намаз укыган (гыйбадәт кылган). Казан ханлыгын Мәскәү дәүләте яулап алгач, бирегә дә баскынчылар – рус православие чиркәве әһелләре, чукындыручылар, миссионерлар – килеп җитә. Соңрак рус крепостной крестьяннары күчерелә. Александр исемле рус алпавыты, барин бу җирләрнең хуҗасы санала. Аның исеме белән авыл атала. XIX йөздә Александровка авылында 238 йорт була, үзәк урамның озынлыгы – 1,5 чакрым. Ул яклардагы Хәтнә (русча Хотня) авылында XIX г. башында алпавыт Перцов Н.П. су ятмасы таба. Хәтнә чыганагының табигый-могҗизаи тәэсире барлык тереклекне җәлеп итә, чөнки аның уникаль үзенчәлеге – табигый көмеш – тәнгә шифалы, организмны тиз сихәтләндерә.

Иске, ләкин матур архитектуралы таш чиркәү янгын вакытында зур зыян күргән, аннары агачтан яңа чиркәү салганнар. Александр байның бик күркәм йорт-җире, гаять зур бакчасы булган: 10 гектар мәйданда бары тик чыршы, нарат һәм каен үскән. Бакчага бер генә юлдан керелгән, бакчаның ике башында ике күл җәйрәп яткан, хәзер алар юк. Бу бакчаны җирле халык “бай бакчасы” дип атаган.

Бу чиркәүле авылның икенче татарча атамасы – *Тыңламас*. Каян килеп чыккан ул? Шулай ук кызык тарих сөйлиләр. Алпавыт Александр авыл старостасы белән сөйләшеп, аларның зур җир кисәген алган (40 гектар чамасы). Авылдашлары бу хакта белеп, старостадан җирне кире кайтаруны таләп иткәннәр. Ләкин ул барин янына тыңламас дип кабат бармаган. Шуннан соң Талнамаз авылын *Тыңламас* дип атый башлаганнар.

XX г. Александровкасының соңгы кешеләре – Тучиннар гаиләсе иде. Алар беркайчан да колхозга кермәгән. Владимир Тучин тирә-юньдә яхшы ветеринар врач саналган. Аны тәҗрибәле белгеч буларак бик хөрмәт иткәннәр. Ул Александровкадан 12 чакрым ераклыктагы Хәтнә авылының ветеринария шифаханәсенә йөреп эшләгән. Владимирның сеңлесе Ольга Тучина 100 яшькә кадәр яшәгән. Өтнә авылында гомер итүче безнең кода Рафис Габделхаков сөйләвенчә, ул әле 95 яшендә кул пычкысы белән агач ботаклары кискән...

Кыскасы, галим һәм язучы Мөхәммәт Мәһдиев кисәтүен һичкайчан онытмыйк, укучым: “...авылларыбызның исемнәрен ачыклаганда бик сак булырга, аларны ачканда нейрохирург кебек эшләргә кирәк”.

“Давыл хәбәрчесе – Иделдә” әдәби-публицистик язмасын [7] бөек рус язучысы Максим Горькийның тууына 120 ел тулуга багышлаган. Укучыны әдипнең татар телендәге тәрҗемә әсәрләре белән таныштыра. М.Горький әсәрләрен ана телебезгә тәрҗемә итү XX г. башында зур вакыйга санала. Бу игелекле эшкә беренче булып Сәгыйт Рәмиев алына. “Давыл хәбәрчесе турында җыр”ның татарча тәрҗемәсенә Галиәсгар Камал да игътибар итә. “Бәхетсез егет” драмасында караклар нәкъ менә шуны – С.Рәмиев тәрҗемәсендәге Горький җырын хор белән җырлыйлар. 1907 елда “Бәхетсез егет” аерым китап булып басыла һәм бу җыр халыкка тарала. Бераздан җыр Казан сәхнәсендә яңгырый – Горький иҗаты безгә шулай җыр булып керә, ди ул.

Шулай итеп, узган гасыр башы татар реалистик әдәбиятына Горький килеп керә. “Татар матбугаты аның исемен еш телгә ала. Горький кем ул? Ул ничек яза? “Вакыт” газетасы Оренбург укучыларына хәбәр итә: “Горький үз бүлмәсендә язганда бөтен дөньясын оныта, бөтен күңеле илә шул әсәренә бирә”. (“Вакыт”, 1907, № 252)”.

1908 елда Горькийның “Ана” романы төрек теленә тәрҗемә ителеп, Төркиядә басылып чыга. М.Мәһдиев аны да игътибарсыз калдырмый: “Татар зыялылары арасында фикер уяна: ни өчен әле без, татарлар, үзебездә яшәгән, безне яраткан, ихтирам иткән Горькийны татарчага тәрҗемә итмибез?”. Горький әсәрләрен тәрҗемә итүче Солтан Рахманколый, Галимҗан Ибраһимов иҗатларына туктала. Кызганыч, Октябрь инкыйлабына кадәр Горький прозасы бөтенләй үк диярлек туган телебезгә тәрҗемә ителми.

“Вакыт”, “Йолдыз” газеталарының Горький иҗатын пропагандалавы мактауга лаек, ди. Бу басмалар танылган язучы турында мәгълүмат бирү өчен рус матбугатына мөрәҗәгать итәләр.

Октябрь борылышыннан соң татар әдәбият белемендә Горький иҗатын өйрәнү, тәрҗемә итү һәм аның белән аралашуның яңа чоры башлана.

“Горький кем ул? Әдәбият дөньясында ул кайсы сыйфаты белән мәшһүр? Бу мәсьәләне 20 нче еллар башында Г.Ибраһимов күтәрә”, – дип яза М.Мәһдиев. Ибраһимовның 1920-1922 еллардагы хезмәтләрен уңай бәяли.

1923 елгы “Безнең юл” журналының 12-нче санында басылган М.Горькийның “Кеше”сен (Нәҗип Думави тәрҗемәсендә) совет чоры татар әдәбиятында иң кыю иректе тәрҗемә әсәре дип атый автор. Галимҗан Нигъмәти “М.Горькийның беренче әдәби хезмәт еллары” мәкаләсе белән татар филологиясендә “Горькийны өйрәнү” юнәлешенә нигез сала. Горький турында В.И.Ленин фикерләрен татар телендә беренче яңгыратучы кеше дә Г.Нигъмәти була. “Безнең язучылар Горькийдан күп нәрсәләргә, әлбәттә, иң *беренче нәүбәттә* (курсив безнеке. – М.М.) язучылыкка өйрәнергә телиләр”. (“Яңалиф”, 1932, № 8)”.

“...(Горькийның бу киңәше (1929 елда Мәскәүдә А.Герцен исемендәге язучылар йортында татар әдипләре белән очрашуда Горький залга килеп кергәч, аңа ихтирам йөзеннән озак итеп кул чапканнар, ул аларга: “Кирәкми, кирәкми, кул чабарга кирәкми, языгыз күбрәк... Сез – язучылар, төп эшегез – язу. Никадәр күп һәм яхшы язсагыз, минем өчен шулкадәр зуррак хөрмәт күрсәткән булырсыз...”, – дип әйткән. – Мирсәй Әмир истәлегеннән. – И.Ф.)) бүген – сиксәненче еллар язучылары өчен дә заманча бит! Күпме язучы үзенең юбилеен артистлар, композиторлар чакырып филармония концертына әйләндермимени?! Гомеренең яртысын кул чаптырып залдан-залга күчеп чыгыш ясап уздырган язучыларыбыз азмыни?)”.

Шул сөйләшүдә Горький бик гыйбрәтле фикер әйткән: “Татар язучыларының кыйммәте – *татар тормышыннан язылган* (курсив безнеке. – И.Ф.) художество әсәрләре тудыруда. Мин татар язучыларыннан кайбер иптәшләрнең әсәрләрен укыганым бар. Алар үзләренең *татар язучылары икәнлекләрен онытып* (курсив безнеке. – И.Ф.) ялгыш итәләр. (Горький монда, күрәсең, К.Нәҗминең “Шобага” хикәясен күздә тота, ул аның тәрҗемәсен 1928 елда укып чыккан була. – М.М.). Татар тормышына хас булган специфик моментларны художество сурәтләре аркылы күрсәтү, формасы белән милли, эчтәлеге белән советчыл булган татар әдәбияты тудыру, шундый әдәбият аркылы татар тормышы белән бөтен дөньяны таныштыру – татар язучыларының төп бурычлары”.

“...безнең татар әдәбияты өстенә күз йөртеп чыксаң, Горький сүзләренә тиешенчә колак салмаганыбыз күренә. Без күп вакытта үзебезнең *татар язучылары икәнлегебезне онытабыз* (курсив безнеке. – И.Ф.), кул чабуларга,

тантаналы сүзләргә бирелеп язучылар икәнлегебезне дә онытып җибәргәлибез әле”. (Әмир М. Горький безгә ни әйтте? “Яңалиф”, 1932, № 8)”.

М.Мәһдиевнең публицистлык осталыгына игътибар итсәк, иҗтимагый-публицистик стильдә гаҗәп дәрәҗәдә иркен язган, мәсәлән: “...Заманнар, җитәкчеләр, кануннар үзгәрә, карарлар чыга, ә Горький һаман бөек булып кала. Инде без аңа шулкадәр ияләнгәнбез, ул гомер буе безнең арада яшәгән, безнең телдә язган сыман тоела безгә. Моның хикмәте нәрсәдәдер, без ул турыда уйлап та тормыйбыз, әмма интуитив рәвештә сизәбез: Горький *олы җанлы кеше* (курсив безнеке. – И.Ф.) булган. Бөек рус язучысы дигән мактаулы исем йөртсә дә, милли әдәбиятларның барысын да тигез күргән, елгалар, каеннар, ашау-эчү әйберләрен, мунчаларны да милләтләргә бүлеп өләшеп язмаган. Кайта-кайта әсәрләрен укысаң, тагы да ышанасың: Горький бөтен иҗаты белән кешеләрне олы җанлы булырга өндәгән икән һәм, *олы җанлылык язучыларыбыз арасында дефицитка әйләнә башлауга*, мәһабәт, саллы гәүдәсе – иҗаты белән безнең алга Максим Горький килеп баса икән”.

Галим мәкаләсеннән фәнни стильгә дә үрнәк табарга мөмкин: “Горький иҗатыннан **осталыкка, халыкчанлыкка, гомумән, сәнгатьчә уйларга, фикер йөртергә өйрәнергә кирәк иде**. Тарих моны исбатлады”.

Монда ул матур әдәбият стилен дә кулланган, мисал өчен: “Элекке Лаеш урманнары, куаклыклары өстенә җәелеп яткан кояшлы, чал Идел өстендә акчарлаклар уйнаган да, җилле-давыллы көннәрдә карачкыл-кургаш дулкыннар куптарып, безнең җаннарыбыздагы ваклыкларга рәнҗегәндәй, ул мәһабәт елга дулаганда да, безгә бөек язучының авазы ишетелә. Давыл хәбәрчесе дигән кош авазы белән кисәтә ул безне:

– Әдәбият – кеше турындагы фән, сәнгать ул. Әдәбият кәсеп түгел, талант иясенең җан авазы ул! Чын мәгънәсендәге әдәбият – батырлык, үз-үзеңне мәҗнүннәрчә шуңа сарыф итү ул! Ә батырларның мәҗнүнлегенә без дан җырлыйбыз....”

Димәк, автор татар язучыларын Горький иҗатыннан үрнәк алырга өнди. “Идел өстендәге Давыл хәбәрчесе кошы шулай һәрчак безнең белән...”, – дип төгәлли.

“Европа – безнең хакта” фәнни-публицистик мәкаләсенең [8] башында ук М.Мәһдиев татар тарихы, мәдәнияте, фольклоры белән кызыксынган француз галимнәре А.Беннигсен, Л.Келькеже Парижда чыгарган белешмәлекне (1917 елгы түнтәрелешкә кадәрге татар матбугаты тарихына кагылышлы), 1980 елда Хельсинкидә “Финляндия төрекләре берлеге” татарча бастырган “Безнең җырлар” җыентыгын, немец галимнәре Отто Гётч,

Готгольд Вайль, фин галиме Һ.Паассонен һ.б.ның хезмәтләрен атап узган. “Европа галимнәре безне белә!” – дип чын күңелдән шатланган.

Автор халкымның тарихы, әдәбияты, авыз иҗаты турында Европада басылып чыккан кайбер гыйльми хезмәтләргә күзәтү ясауны максат итеп куйган. Аерым алганда, венгр галиме Балинт китабына киңрәк тукталган:

“Балинт Габор 1844 елда туган (мадьяр телендәге әдәбиятта кешенең фамилиясе башта, исеме икенче булып китерелә). Вена һәм Будапешт университетларының хокук факультетында укыган чагында, ул бар булган буш вакытын телләр өйрәнүгә багышлый, бигрәк тә көнчыгыш телләре белән кызыксына. 1870 елда ул күпсанлы мадьяр сүзлекләренең редакторы булган академик Фогараши Янош белән таныша. Аның киңәше буенча Балинт монгол һәм рус телләрен өйрәнә башлый. Фогараши ярдәме белән Балинт Россия һәм Азиягә өч еллык сәяхәткә китә, аның юл расходларын Венгрия Фәннәр Академиясе күтәрә. Балинт Казанга 1871 елның 17 июнендә килеп җитә, тиз генә эшкә керешә. Казанда ул иң әүвәл миссионер Ильминский белән таныша, керәшен татарлары укыган мәктәпләргә йөри башлый. Тел үрнәкләре язып алу өчен иң уңай алым – халык иҗаты әсәрләренә мөрәҗәгать итү икәнен Балинт яхшы аңлый. Ул Лаеш, Мамадыш, Казан өязләренә йөри, халык иҗаты әсәрләрен язып алуда Гаврила улы Борис исемле керәшен ярдәм итә. Ул җыйган материаллар 1875 елда Будапештта аерым китап булып басылып чыга (Kazani tatar. Balint Gabor, Budapest, 1875. Чит телләрне өйрәнү. Текстлар һәм тәрҗемә. Җыючысы һәм тәрҗемә итүчесе Балинт Габор). Балинтның китабына барлыгы 144 мәкаль, 46 табышмак, 64 кыска җыр, 4 бәет (кайберләрен Ильминскийның шәкерте Тимофеев Игнатий Бачлей улы әйтеп яздырган), 34 әкият һәм керәшен татарларының ышана торган кирәмәтләре тупланган. Болардан тыш китапка изгеләр сүзләре, дини риваятьләр кертелгән”.

Бу китапның 1875 елгы басмасының бердәнбер нөсхәсе Казан университетының фәнни китапханәсендә бар. Гомумән, венгр галимнәре татар фольклоры белән ныклап кызыксыналар.

1980 елда Кәкүк Жужа ханым “Казан татарларының халык җырлары” китабын бастырган (алман телендә, Kazan tatarische volkslieder. Zsuzsa Kakuk, Budapest, 1875). Бу җыентыкка Кунош Игнац 1915-1918 елларда Австро-Венгрия империясендә тоткынлыкта булган татар хәрби әсирләреннән язып алган 643 җыр кергән. Татар җырларының текстына янәшә рәвештә аларның алман теленә тәрҗемәсе дә бирелгән. Балинт китабында да шулай. “Мондый алым Европа галимнәренең бик күбесенә халкыбызның акыл байлыгы,

эстетик фикерләү дәрәҗәсе белән танышырга мөмкинлек бирә”, – дигән М.Мәһдиев.

Венгриянең Сегет университетындагы Урал-Алтаистика кафедрасы мөдире Берта Арпад Балинтның татар фольклорына багышланган бөтен китапларының яңа җыентыгын бастыра (A.Berta. Budapest, 1988, 412 p.). Хезмәтнең “Сүз башы”нда Балинтның тормыш юлы хакында бай мәгълүмат тупланган, фәнни аппаратында татар халык иҗатына караган европа чыганаклары да күрсәтелгән, ди.

Түбәндәге өзекләрдә М.Мәһдиевнең галимлеге ап-ачык сизелә:

“Балинт татар халкының шулкадәр затлы җырларын, мәкаль-әйтемнәрен җыйган ки, хезмәт халкының акылына, эстетик фикерләү дәрәҗәсенә таң каласың. Әле бит 1905 ел революциясе дә булмаган, татар халкының газета-журналлары да, театры да юк. Ә халык үз язмышы турында фәлсәфи фикер йөрткән, сөю-нәфрәт хисләрен – җырларында, акылын, тормыш тәҗрибәсен – мәкаль һәм табышмакларында, матур хыялын – экиятләрдә, моң-зарын бәетләрдә гәүдәләндергән”.

Б.Габордан бер җыр куплеты мисалга китерә дә болай аңлата:

“Кара да постау чикмәнемне
Кара ефәк белән бөккәндер;
Тәрәзәләреннән карый-карый
“Әллә кайтыр” диеп көткәндер.

Сиздегезме? Халык гел чабата-башмактан гына йөрмәгән, ямаулы күлмәктән генә дә түгел. Постау – “Бостон” – костюм тектерә торган югары сыйфатлы чын йон материал, гадәттә кара төстә була. Моны Америкадагы Бостон шәһәре тукучылары эшләп чыгарган. Татар агаеның чикмәне әнә шул “бостон”нан. Алай гына да түгел, ул әле бөрмәләрендә кара ефәк белән дә бизәлгән...”

М.Мәһдиев “теш карасы” төшенчәсен Балинт китабыннан татар җыры китереп шәрехли:

“Теш караларын бик сөям,
Тиерәсем килми тешемә;
Сөймимен түгел, бик сөям,
Белгертәсем килми кешегә”.

Галим теш карасын XIX йөздә – XX г. башында затлы татар кызлары тешләрен кап-кара сөрмәгә (ялтыравыклы лакка) буяганда куллануын, әнисенең дә кыз чагында тешләрен сөрмәгә буяганын әйтеп үтә.

Б.Арпад 1988 елның 7 декабрендә Миркасыйм Габделәхәт улы Госмановка автограф белән бүләк иткән китабында галимә астына сызган бер

татар мәкаленә М.Мәһдиев тә игътибар иткән: “Күргәнне *кютләген* (ишеткән) җиңгән”. Кютләген сүзен галим ачыкларга тырышкан. Аныңча, бу мәкальдә хата бар. Ул аны “Күргәнне *киртләгән* җиңгән” дип дөресләгән. Гаврила улы Борис исемле керәшен татары җыйган материаллардан күчереп язганда Балинт киртләгән сүзен аңламаган, шуңа күрә хаталы язган дип саный. Фикерен дәлилләп, туган телебездәге “Колагыңа киртләп куй” әйтемен мисалга китергән. Моны ул үзе өчен гыйльми ачыш дип исәпләгән.

Галим уйлавынча, Сегет университеты тюркология фәненә зур игътибар бирә. Урал-Алтаистика кафедрасы әзерләп чыгарган “Татар этимологиясе” җыентыгын (1988) мисалга китерә. Тугандаш татар-башкорт телләренең кайбер мәсьәләләрен тикшерүгә багышланган әлеге хезмәткә мадьяр галимнәре Й.Торма, А.Рона-Таш, Л.Тардь, алман галиме К.Шёниһ белән бергә татар галимнәре Альфред Халиков, Рифкать Әхмәтҗановның да фәнни нәтиҗәләре кергән.

Мәкаләсенә йомгак ясап, М.Мәһдиев үзенең публицист рухына, публицистик фикерләү рәвешенә, акыл дәрәҗәсенә һәм шәхси өслүбенә хас булганча гына болай ди:

“Европа безнең хакта күп яза. Телебез, әдәбиятыбыз, тарихыбыз, яшәү рәвешебез турында. Безне яратып язучылар күп, яратмаучылар да җитәрлек, дидек. Ләкин фән, гыйлем андый симпатия, антипатияләрдән өстен торырга тиеш. Без исә үзебез турында кайда нәрсә чыкканын белмичә яши бирәбез. С.Рәмиев әйткәнчә, “татар йоклый”. Без һаман әле уяна алмыйбыз, авырлык белән генә күзне ачабыз да яңадан ойыйбыз. Югарыда китерелгән хезмәтләр безне дә активлыкка чакырмыймыни? Татар теле галиме дигән төшенчә галимнең рус, гарәп, немец, төрек, мадьяр, инглиз, француз телләре белән эш итә алучы кеше икәнлеген таләп итмимени? Кайда безнең мадьяр телен өйрәнгән тел галимебез? Ә бит мадьяр Балинт, рус Чернышевский татар телен белгәннәр. Кайда немец телен, инглиз, гарәп, төрек, француз телләрен иркен белгән тюркологыбыз? Ә бит проф. Н.Ф.Катанов сигезләп телне белгән, татар галимнәренә гарәп шрифтында татарча хатлар язган...”

Әлеге мәкаләсе белән автор татар галимнәрен активлыкка чакыра: “Европа гыйлеме безгә күз тутырып карый, элемтә эзли. Ә без... качабыз, оялабыз”.

“Өлкән әдип белән очрашуларым” мәкаләсе [9] Сәйфи Кудаш турындагы истәлекләрдән гыйбарәт. “Сәйфи ага Кудашны беренче тапкыр күрүем алтмышынчы еллар башында булды”, – дип башлап китә. Бу вакытта М.Мәһдиев КДУ аспирантурасында укый: 1917-1932 елларда татар әдәби тәнкыйтенең барлыкка килүен, үсүен өйрәнә. Казан, Уфа, Мәскәү, Свердлов

шәһәрләрендә басылган барлык татар газета-журналларын укып чыга. “Мәктәптә укыган елларны безгә, әдәбият дөньясында дүрт галим бар, дип өйрәткәннәр иде. Болар – Мөхәммәт Гайнуллин, Гали Халит, Хәй Хисмәтуллин һәм Хәсән Хәйри. Ә мин актарган газета-журналларда безнең буын ишетмәгән йөзләрчә исем... Кая барырга, кемнән анықларга?”, – дип сорый ул.

Дөньяда иң хәтерле кеше Афзал Шамов дигәч, публицист аны эзләп китә. Ул аңа С.Кудаш белән очрашып сөйләшергә тәкъдим итә. М.Мәһдиев икенче көнне үк “Казан” кунакханәсендә өлкән әдип белән очраша. Ике сәгать барган аралашудан яшь галим кандидатлык диссертациясе өчен күп мәгълүмат ала, зыялы булу өчен үзенә һәм галим-голәмәгә нәрсә җитмәгәнлеген аңлый. Сөйләшүдән соң М.Мәһдиев мондый нәтиҗәгә килә: “Интеллигент булу өчен *каршыңда утырган кешене тыңлый белү дә* (курсив безнеке. – И.Ф.) бик кирәк икән”. Шушы очрашуда С.Кудаш аңа Г.Ибраһимов, Г.Нигъмәти, Хәлим Искәндәрев, Хөсни Ишбулатов, Галә Ходаяров кебек әдәбиятчы-тәнкыйтьчеләр турында дөнья кадәр мәгълүмат бирә. Остаз күрсәткән юлдан китеп, 15-20 ел эчендә М.Мәһдиев әдәбият тарихы буенча бай материал туплый. “Сәйфи ага мине әнә шулай мәңгелек эзләнү бәхетенә – мәшәкатьле, борчулы бәхет дөньясына юнәлтте”.

С.Кудаш Казанга дусларын сагынганга күрә генә еш килеп йөргән. “Икенче, өченче очрашканда без инде – остаз һәм шәкерт – кемгә нәрсә кирәген, кемнең нәрсә бирә алганын яхшы белә идек”, – ди галим.

Автор әлеге язмасында Х.Туфан җыйган мәҗлестә С.Кудаш белән очрашуын шактый тулы итеп, диалог рәвешендә тасвирлый:

“Гомәр Бәширов, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким яшәгән “Аккош күле” дачасының җәйге бер көне аеруча хәтердә калган: язучы хатыннары йөгерешә – кемдер гөбәдия пешерә, кемдер токмач кисә, язучылар дача капкасы төбендә йөренәләр: ни бар, нәрсә булган?

– Сәйфи ага килә, Сәйфи!

– Кит аннан! Сәйфи Кудаш үземе?

– Үзе инде, үзе! Кичә аэропортта каршы алдык, менә бүген аны Союз машинасы белән монда китерәчәкләр.

Менә дача капкасыннан мөлаем чырай белән мәһабәт гәүдәле Сәйфи ага килеп керә. Затлы киемнән. Сәйфи аганы кайда утырту турында ярты секундлык кына бәхәс, менә Хәсән Туфанның балаларча саф шатлануы...

Сәйфи аганы яраткан темасына тиз тартып керттеләр: Мәҗит Гафури, Шәехзадә Бабич, Сәгыйть Рәмиев, Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, Мулланур Вахитов...”

“Каһәрләнгән хәрәкәт, каһәрләнгән тема...” мәкаләсендә [10] М.Мәһдиев “Иж-Буби процессы” дигән гаҗәеп серле тема хакында яза. Аның буенча совет матбугатыннан да байтак мәгълүмат таба. Бу теманы татар әдәбияты кафедрасы планына диплом эше итеп кертә. “Максатым – Лобачевский исемендәге китапханәдә саклანучы Г.Буби кулъязмаларын һәр елны берәр студенттан күчертеп, шуңа сүз башы, текстологик анализ, сүзлек биреп, ахырдан бу кыйммәтле хәзинәне аерым китап итеп әзерләү иде.” Галим бу теманы студент Ф.Казнинага тәкъдим итә. Ул диплом эшен намус белән башкарып чыга, ләкин әлеге хезмәткә “яхшы” билгесе генә куела. Сәбәбен М.Мәһдиев кафедра мөдире булмавында күрә.

“Буби мәдрәсәсе” мәкаләсен 1960 елларда ук “Казан утлары” журналына бирә. Редакция аны рецензияләү өчен Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына җибәрә. М.Мәһдиевнең “Тарихның бер тармагы” мәкаләсенә 1968 елның 3 гыйнварында Г.Ибраһимов исем. ТӘһТИ өлкән фәнни хезмәткәре Хөсәен Хәсәнев язган бәяләмәне [10] укучы игътибарына тәкъдим итә. “Искәрмәләр төп ике төркемгә бүленәләр: а) “Бубилар хәрәкәте” дигән төшенчә дөрес түгел. “Хәрәкәт” бары тик революцион гына, пролетариатларча гына була ала; б) Бубиларның эшчәнлеге сыйнфый характерда булмаган: монда пантюркизм, панисламизм идеяләре көчле булган”.

“Татар зыялысы... Ул – кем?” мәкаләсенә [11] эпиграф итеп М.Мәһдиев даһи Тукайның “Бәгъзе зыялыларымыз” шигырен ала:

“Татар халкы арасында хисапсыз күп зыялылар.
Сирәк ләкин, дөрест әйтсәм, кешелекле, хәялылар.

Әгәр күрсәң, кызарган йөз аларда, бер дә алданма;
“Оялгандыр!” димә яңлыш, “җибәргәндер” дисәң – әүля!

(Сүзлек: бәгъзе – кайбер, хәялы – ояты, вөҗданы булган кеше; “җибәргәндер” – эчкән мәгънәсендә; әүля – дөресрәк.)”.

Баш исемендә үзе куйган риторик сорауга автор төгәл җавап бирү белән башлый: “Беркем дә түгел, бүген татар зыялысы юк”.

Болай кыю итеп М.Мәһдиев кенә әйтә алган, мөгаен. Публицистик мәкаләсенең башыннан ахырына кадәр җавабын исбатлап, байтак дәлилләр китергән. Аныңча, моның сәбәпләре тарихта. Бу – безнең татар милләтенең генә түгел, бәлки Россия империясенә кергән барча халыкларның да фаҗигасе. Хакимияткә кем генә килмәсен, иң әүвәл ул үзен зур интеллигент итеп күрсәтергә тырышкан, чын интеллигентны таптаган, бетергән. “Интеллигентлык – рус төшенчәсе” дигән фикер аңа ошамый. “Ник, нишләп

алай булсын? Татарны канга батырып, чукындырып йөргән православие миссионерлары интеллигент буламы? Юк, интеллигент ул – кешене, аның динен, телен, гореф-гадәтләрен ихтирам итүче кеше юк, интеллигент татарда гына түгел, русның үзендә дә юк.”

Зыялылык – тирән төшенчә, ярым-йорты була алмый. Ул сыйфат кешедә йә бар, йә юк. Моңа мисал итеп М.Мәһдиев классик әдип, сәләтле прозачы, “Галия” мәдрәсәсеннән бераз укыгач куылган, тәмамламаган югары дини белемле, “Аң” журналында эшләгән, аннары “Галия”дә үзе укыткан Г.Ибраһимовны китергән. Аның фикеренчә, татар халкының үзаңына Тукай иң кирәк чакта – көрәш мәйданында – аңа аяк чалган; Газиз Гобәйдуллинга, аның нәселенә каршы мәкаләләр бастырган Г.Ибраһимов берничек тә интеллигент була алмый. Г.Тукай, К.Тинчурин, Г.Камалларны да М.Мәһдиев зыялылар рәтенә кертми. “Тукай да иҗатының беренче чорында әле зыялы түгел. Яшь егет сатирик журналларда әледән-әле Йосыф Акчура, Фатыйх Кәрими, Габдерәшит Ибраһимов, Исмәгыйль Гаспринский кебек татар халкының бөек улларын тешләп-тешләп ала. Хәтта Гаяз Исхакыйны да тешләп уза. Ләкин яшь егетнең бу мавыгуларын гафу итик. Без генә ул, хәзер, арткы акыл белән (“задним умом”) акыллы. Тукайда, еллар үткәч, прозрение (күзе ачылу) була.”

1919-1920 елларда татар укымышлыларының каймагы – Г.Исхакый, Й.Акчура, С.Максудый, Габдулла Баттал Таймас һ.б. – мөһаҗирлеккә киткән. Алар рус, төрек, француз, инглиз, алман, гарәп, фарсы телләрен камил белгән. Казан Г.Гобәйдуллинны да, Г.Сәгъдине дә, чын зыялы М.Галәүне дә сыйдырмый. М.Галәүнең ике романын Казан басмый, ул аларны бастырыр өчен Мәскәүгә китә, романнарын үзе русчага тәрҗемә итә.

М.Мәһдиев ачынып, болай төгәлли: “Безнең буында булмады инде ул зыялылар. Ләкин милләтебез киләчәктә бу катлауны эшләп чыгарырга тиеш. Зыялылары булмаган көе Татарстан дәүләте яши алмаячак. Ә зыялы кеше – ул, уйлавымча, үз мәнфәгатьләрен кайгыртмыйча милләт өчен көрәшүче белемле, юридик әзерлекле, әхлакны белгән, ачык күзле, хөсетсез бер татар баласы. Ул туар, үсәр, Татарстаныбызга хезмәт итәр”.

“Кара тарихтан бер ләүхә” мәкаләсе [12] Миргазиз Укмасыйның тууына 140 ел тулуга багышлана. Публицист әлеге язмасын Сахалин утравыннан Татарстанның Язучылар Берлеге идарәсенә хат килү турында хәбәр итүдән башлый. Хат эчендә тагын бер хат була. Хатларның берсе М.Укмасыйныкы, икенчесен оныгы язган. Мәкаләнең бурычын М.Мәһдиев үзе үк билгели: “...шагыйрьнең биографиясендәге ак тапларга төс бирү”.

М.Укмасый исеме 1920-1940 елларда телгә алынмый. Ул 1945 елда “Совет әдәбияты” журналында күренә. 1956 елда КПССның XX съездында Сталинның шәхес культы фаш ителгәч, татар әдәбиятында зур вакыйга була: шул ук елда “Татар поэзиясе антологиясе” басыла. Анда М.Укмасыйның биографиясе бирелә, әмма Сталин өрәге яши әле: М.Укмасый әсәрләренә сүз башы язган Мөхәммәт Гайнуллин аның сәяси репрессия корбаны булуы турында әйтми. 1986 елда чыгарылган “Совет Татарстаны язучылары” дигән белешмәлектә дә бу хакта ләммим. Югыйсә, 1920-1940 елларда кайда булган ул, әсәрләре ник басылмаган дигән хак сорау куя автор.

М.Укмасый хәзерге Балык Бистәсе районының Укмас авылында 1884 елда туа, хатыны – Күгәрчен авылы мулласы кызы. Аның исеме матбугатта беренче мәртәбә 1906 елда күренә. Тәнкыйтьче буларак мәкаләләр яза, татар әдәбиятын чүп-чар әсәрләрдән чистартырга чакыра, Г.Тукайга ияреп, тәнкыйть кирәклеге фикерен кабатлый. Тәнкыйтьнең әдәбиятта тоткан урынын билгеләп, Европа әдәбиятының бары тик тәнкыйть аркасында гына чәчәк атуын искәртә.

Укмасыйны заманында Тукай телгә ала. Ул 1910 елда Шәрык клубында сөйләгән лекциясендә М.Укмасыйның “Килен” шигыре халык иҗаты нигезендә язылганлыгын әйтә, аны мөнбәрдән укый.

“Татар поэзиясе антологиясе”ндә М.Укмасый 1947 елда вафат дип язылган, ләкин чынлыкта ул 1946 елның көзендә үлгән. Моны М.Мәһдиев бездә кеше кадерен белмәүнең ачык мисалы дип аңлата.

Шулай итеп, без М.Мәһдиевнең 1985-1995 еллардагы публицистикасын анализлагач, мондый нәтиҗәләргә килдек:

а) мәкаләләрен өйрәнү М.Мәһдиев бу чорда татар публицистикасын үстерүгә зур өлеш керткән дигән фикеребезне раслады;

б) публицистның үз стиле бар, аның сүз һәм фикер сөрешенә кыюлык хас;

в) журналистик-публицистик, фәнни, матур әдәбият стильләрендә җиңел язган, бер үк мәкаләдә аларны аралаштырып кулланган;

г) публицистик мәкаләре М.Мәһдиевнең олы җанлы кеше, әхлаклы һәм зыялы шәхес, затлы нәселдән булганлыгын исбатлый;

д) әдәбият галиме буларак, ул тирән филологик белемгә ия, укымышлы һәм мәгълүматлы белгеч.

## Кулланылган әдәбият

1. Горький М. Несвоевременные мысли: Заметки о революции и культуре; Рассказы / Сост. А.В.Диенко; Худож. М.В.Осипова. М.: Современник, 1991. 128 с.

2. Фәтхерахманов Р. Тормыштан килгән геройлар (Мөхәммәт Мәһдиев әсәрләренең өчтомлыгы чыгу уңаеннан) // Казан утлары. 1996. № 10. 149 – 158 б.

3. Мәһдиев М. Мәшәкатьле һөнәр // “Идел” альманахы. 1984. № 4. 75 – 78 б.

4. Мәһдиев М. Миңа 195 яшь (М.Мәһдиев үзе турында) // Ватаным Татарстан. 1995. 15 март.

5. Учёнова В.В. Публицистика и политика: 2-е изд., доп. М.: Политиздат, 1979. 271 с.

6. Мәһдиев М. Туган як авазы // Казан утлары. 1988. № 6. 178 – 181 б.

7. Мәһдиев М. Давыл хәбәрчесе – Иделдә (М.Горькийнең тууына 120 ел) // Казан утлары. 1988. № 3. 170 – 178 б.

8. Мәһдиев М. Европа – безнең хакта // Казан утлары. 1990. № 2. 152 – 155 б.

9. Мәһдиев М. Өлкән әдип белән очрашуларым // Казан утлары. 1991. № 10. 186 – 187 б.

10. Мәһдиев М. Каһәрләнгән хәрәкәт, каһәрләнгән тема... // Казан утлары. 1993. № 2. 141 – 146 б.

11. Мәһдиев М. Татар зыялысы... Ул – кем? // Казан утлары. 1993. № 10. 142 – 146 б.

12. Мәһдиев М. Кара тарихтан бер ләүхә (М.Укмасыйның тууына 140 ел) // Казан утлары. 1994. № 12. 167 – 170 б.

## Белемнәрне тикшерү өчен сораулар, мөстәкыйль эшкә биремнәр

1. Публицистик осталыкны формалаштыра торган чараларны әйтегез.

2. М.Мәһдиевнең публицистлык осталыгының үзенчәлекләрен ачыклагыз.

3. М.Мәһдиевнең бер публицистик мәкаләсен анализлагыз.

## VI бүлек. М.Мәһдиев дөньясына бер караш

*Татарстан халык язучысының*
*80 еллыгына багышлыйм.*
*Автор.*

Узган 2010 елгы шомлы, афәтле җәйнең эссе бер көнендә туган авылымдагы салкынча һавалы нарат өйдә галим һәм язучы Тәлгат Галиуллинның затлы каләменнән ак кәгазьгә төшкән гаҗәеп язмасын укыдым – “*Мөхәммәт Мәһдиев дөньясы*” [1] белән таныштым. М.Мәһдиевнең мәшәкатьле, ыбыр-чыбырлы тормыш юлын бераз белсәм дә, шәхсән үзем өчен әдипнең эчке дөньясын яңадан ачтым.

Һич арттырып, күпертеп яки ярарга тырышып әйтүем түгел, мин бу очракта гади укучы буларак таң калдым Тәлгат абыйга: элекке якын дусты, хезмәттәше Мөхәммәт Сөнгатулла улы Мәһдиев шәхесенә карата искиткеч кешелеклелек сизелә, татар кешесенә хас киң күңеллелек ярылып ята, шәп хәтер саклanган. Тәлгат Галиуллин хәтеренең ныклыгына, иманының көрлегенә шаккатарлык! Автор Мәһдиев белән бергә катнашкан чараларны, узган вакыйга-хәлләрне бөтен нюансларына кадәр тәфсилләп тасвирлый. Аңарда тел куәсе, сүз байлыгы гаҗәп зур: дусларча шаяртып кинаяле көлә, мәзәк тә сөйли, тыгыз яза белә, төртмәлелек ярдәмендә тәнкыйтьли дә, ачы хакыйкатьне сурәтләп бирә, мине һәм тагын әллә кемнәрне телгә ала... бар да бар. Кыскасы, Т.Галиуллинның үзенчәлекле мәкаләсен, һичшөбһәсез, хәзерге татар әдәбият белемендә яңа сүз – *әдәби ачыш* – дияргә мөмкин!

...Ачы хакыйкать дигәннән, “халык дошманы” баласы, мулла малае дип йөртелгән М.Мәһдиев, чынлап та, үз гомерендә шактый кыерсытылган, мәсәлән: Балтыйк (*Балтия*) хәрби-диңгез флотында хезмәт иткәндә замполит аңа фамилиясен алыштырырга тәкъдим иткән яки Казан дәүләт университетында укытканда инде язылып беткән докторлык диссертациясен профессор Хатип Госман кире сүттергән – яклау өчен яшел ут кабызмаган. “Ачы тәҗрибә” истәлекләр китабында Мәһдиев мондый гаделсезлекләр хакында гарьләнеп, каләмен ачы күз яшьләренә манып язды. Ул үткән заманнарга хак бәясен биреп, гадел хөкем чыгарды.

Биредә шунысын да искәртү дөрес булыр: әлеге истәлек-мәкалә М.Мәһдиев дөньясының күпләр өчен яңалык саналырлык кызыклы, серле якларын яктырта һәм атаклы авылдашым, күршем хакында мине дә уйга сала. Бу язма-хатирәмне мәрхүмнең якты истәлегенә багышлыйм.

Мөхәммәт Мәһдиев Тәлгат Галиуллинның җан дусты иде. Икесе дә, минемчә, сөекле милләтебезнең соңгы могиканнары. Алар Гомәр Бәширов, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким кебек олпат затларның күңел нурын үзләренә сеңдереп һәм әдәбият аксакалларыннан хәер-фатиха алып, остазлары иҗатын рухи байрак итеп күтәрделәр. Өлкән буын язучылар яшь каләмдәшләре өчен караңгы төндәге маяк шикелле иде. Т.Галиуллин, Алабуга педагогика институты ректоры булып эшләгән чорда, бөек татар әдәбиятының йөзек кашларын милли җанлы мөгаллим һәм студентлар белән очрашуга чакырып, язучылар хөрмәтенә әдәби кичәләр еш оештырган. Шул чакта ук ул Мәһдиев белән дә якынрак таныша, тора-бара ике арада дустанә мөнәсәбәтләр урнаша. Соңрак Тәлгат абый Казан университетына укытырга күчкәч, дуслык җепләре тагын да ныгый һәм алар чын дусларга әйләнәләр.

Мөхәммәт абый йомшак һәм саф күңелле кеше иде. Мин күренекле авылдашым белән ихластан горурланам! Дөресен әйтим, ул миңа киңәш-фатихасын биреп калдырды. Арча районының Г.Камал исемендәге Сикертән урта мәктәбе укытучы һәм укучылары белән соңгы мәртәбә күрешүендә халык язучысы КДУда белем алучы авылдашын өмет белән искә алган икән. (Әнием шулай дип сөйләде.) Бервакыт язын “alma mater”ның 11 нче катында акрын йөри торган лифтны көтеп торганда мин Мөхәммәт Сөнгатович белән очраштым, ул Тәлгат Нәбиевич белән бергә иде. Шунда Мөхәммәт абый миңа елмаеп сәләм бирде һәм эндәште: “Күрше, авылга кайткач, безнең йортны да карап кил әле, төз лапас түбәсен кар басмадымы микән?”

Хәзер “арткы акыл” (*задний ум*) белән уйлап утырам. Мәрхүмнең шул бер җөмләсенә никадәр тирән мәгънә салынган бит: мине якын итеп күрше дип мөрәҗәгать итүе, туган авылын сагынуы, туып-үскән нигездә яшәп һәм аны күз алмасы кебек саклап гомере буе башлангыч мәктәптә укыткан Равия апасы өчен кайгыру хисе...

Гөберчәктән икәнне белгәч, өлкән курс студентлары миңа исемем белән эндәшмичә, яратып “Мәһди” дигән кушамат тактылар.

Минем фикеремчә, биш гасыр буе якты киләчәккә яңа өметләр баглап яшәүче халкымның пассионарлык көче М.Мәһдиевтә ургылып торды, чөнки ул чыгышы белән XIX г. ахыры – XX г. башы татар ак муллалары нәселеннән иде. Шуңа күрә иҗатыннан зыялы нәселләргә генә хас затлылык, татарча фәлсәфи фикерләү, милли моң бөркелә. Безнең авылда аның әтисенә олы хөрмәт йөзеннән мулла абзый дип эндәшкәннәр. Ул данлыклы Күлтәс мәдрәсәсендә (хәзерге Арча районы) гыйлем алган, мөхтәрәм казый, мөфти Ризаеддин Фәхреддин имзасы куелган “имам-хатиб-мөдәррис” дипломы һәм Уфа Үзәк Диния Нәзарәтенең мөһере сугылган указ нигезендә Гөберчәктә

1928 елга кадәр мулла булып торган. Җитмеш ел буе бөек дип макталган Октябрь инкыйлабыннан соңгы кискен иҗтимагый-сәяси борылыш аркасында муллалыкны калдырырга мәҗбүр ителгән. 1929 елда авылда күмәкләштерү башлангач, Советлар кешелексез метод кулланып, аны хәләл җефете һәм җиде баласы белән үз йортларыннан кечкенә бер өйгә күчергәннәр, ә шәхси милкен (сыер, мунча, тагын әллә ниләрен) талап сатканнар. Авылның иң ихтирамлы, иң белемле кешесен большевиклар шул рәвешле мәсхәрәләгәннәр. Кызганыч, гыйлем иясенең кадере калмаган заман иде. Шушындый кыргый гамәлдән соң Октябрь революциясенең бөеклеген исбатлап кара әле син, замандаш?!

Сөнгатулла абзый муллалыктан киткәч, фаҗигале рәвештә өзелгән гомеренең азагына кадәр умартачылык белән шөгыльләнгән. Төрле төстәге болын чәчәкләре үскән печән бакчасында умарталар тотып, кортларның тигез гөжләп бал ташуын зур канәгатьләнү белән тыңлап, Аллаһның Коръән китабында аерым сүрә багышланган бу файдалы бөҗәккә сокланып яшәгән. Ул күп нәрсә турында мәгълүматы булган кеше, чөнки күп укыган: Габдулла Тукай шигырьләренең байтагын яттан белгән, Фатыйх Әмирхан, Лев Николаевич Толстой әсәрләрен яраткан. Мич чыгарырга өйрәнгән.

1937 елның октябрендә СССР Югары Советына депутатлар сайлау өчен агитация башланган. Агитаторлар авылда сәяси активлык күрсәтеп, мәчет бинасына урнашкан клубта сайлаучылар белән очрашканнар. Безнең сайлау округыннан депутатлыка СССР Фәннәр Академиясе академигы Отто Юрьевич Шмидт кандидатурасы күрсәтелгән булган. Мәгълүматлы кеше буларак, илдәге политик ситуациядән хәбәрдар, сәяси аңлы мулла абзый җыелышка килгәч, кызыксынып президиумга катлаулырак сорау биреп ташлаган. Ләкин тегеләр халык алдында компетентлы җавап кайтара алмагач, кызарып бүртенгәннәр. Шул ук көнне президиум әгъзалары Эчке Эшләр Халык Комиссариатының Арча район бүлегенә шикаять язганнар. Ул документны Милли архивтан Мөхәммәт абый үзе эзләп тапты, имза куйган өч коммунист *авылдашның* исемнәре билгеле. Монда ирексездән “татар башын татар ашар” димичә һич мөмкин түгел!

Сөнгатулла Мәһдиев 1937 елның 19 декабрь төнендә НКВД тарафыннан кулга алынып, шул ай ахырында “өчлек” суды карары белән Казан Кремле астындагы Черек күл төрмәсе подвалында атылган. Кабере билгесез...

Ни өчен большевиклар шундый явызлык кылганнар соң? Партиянең белем ягыннан наданрак коммунистлардан торган җирле оешмасы сәләтле көндәштән – сайлаучы мулла абзыйдан – курыккан чөнки. Болай уйларга тулы нигез бар.

1937 елның 23 февралендә башланып, унбер көн буе барган партия Үзәк Комитеты пленумында ясаган докладында Жданов (Сталинның иң якын фикердәше, идеолог, димәк, юлбашчы карашын чагылдырган), катнашучыларны гаҗәпкә калдырып, альтернатив сайлау турында сөйләгән, ягъни Верховный Советка сайлау үткәрү тәртибен аңлатып, сәяси “ятимнәр” өчен теләсә нинди чикләүләр алып ташланачак, “бюрократик органнар” бетереләчәк, совет оешмалары эшендәге хаталар төзәтеләчәк, иң мөһиме – дошманчыл кандидатларга һәм дошман рухындагы агитациягә каршы партия органнары “сайлау көрәшенә әзер булырга тиеш”, дигән. Гражданнарның СССР Конституциясендәге (1936) сайлау һәм сайлану хокукын тулысынча тәэмин итү, кыскасы, демократияләштерү күздә тотылган. Докладчы партия демократиясе принципларын расларга, “исемлек” белән тавыш бирүне юкка чыгарырга, ачык тавыш бирүдән яшерен тавыш бирүгә күчәргә тәкъдим иткән.

Сталин доклады исә партия бюрократиясен үзгәртеп коруга юнәлтелгән. Бу төбәк җитәкчеләренә ниндидер тонык, артык теоретик формадагы сигнал була. Ләкин фикер алышуда чыгыш ясаган Я.А.Яковлев, Г.М.Маленковтан башка унбиш кеше мәсьәләнең асылын да аңлап бетермичә “дошманнар, троцкийчылар” эзләүне активлаштырырга кирәк, дигәннәр. Бу бәхәстә күпчелек тарафыннан җиңелгән Сталин (һәм аның төркеме) үзенең йомгаклау сүзендә партия бюрократиясе властен киметүгә караган берничә рекомендация әйткән, мәсәлән: партоешмаларны хуҗалык эшеннән азат итәргә; күпләп “чистарту”ны туктатырга; партоешма секретарьләренең сәяси белемен күтәрергә; аларны алыштыру өчен кадрлар резервы булдырырга һ.б.ш. Ул партократиядән яңача фикер йөртүче белемле, энергияле, көчле кадрлар куюны таләп иткән.

Нәтиҗә ясап әйтсәк, урыннардагы партаппарат чикләнмәгән властьне үз кулыннан ычкындырмас өчен сәяси оппонентларын “халык дошманнары” дип күпләп юк иткән, шул рәвешле, Мәскәү Кремле тәгәрмәченә таяк тыккан – ҮК сәясәтен партиянең җирле оешмаларына дөрес аңлатмаган, тиешле дәрәҗәдә үтәмәгән. Мондый фикерне беренчеләрдән булып тарихчы Ю.Н.Жуков исбатлый [2, 466-471].

## Кулланылган әдәбият

1. Галиуллин Т.Н. Мөхәммәт Мәһдиев дөньясы // Идел. 2010. № 4. 54-62 б.; № 5. 60-72 б.

2. Рыбас С.Ю. Сталин: 2-е изд. М.: Молодая гвардия, 2010. 902[10] с.: ил. (Жизнь замечательных людей: сер. биогр.; вып. 1219).

## VII бүлек. Тәлгат Галиуллинның иҗат портреты

Тәлгат Галиуллин... Бүгенге татар әдәбиятында еш яңгырый торган бу мөхтәрәм исемне әйтүгә күз алдыма олпат зат: мәһабәт гәүдәле, нык җилкәле, төз муенлы, киң маңгайлы, үткер күзле, көләч йөзле, мөлаем карашлы, чәченә ак бәс кунган, өстенә һәрвакыт елкылдап торган, яңа гына энәдән-җептән чыккан бостон костюм-чалбар, крахмалланган якалы, яхшы сыйфатлы ап-ак күлмәк кигән, югары зәвыкъ белән генә сайлап, муенына күз явын алырлык галстук бәйләгән зур шәхес килеп баса. Беренче күрешүдән үк Тәлгат Нәбиулла улы Галиуллинның сурәте хәтеремә шулай сеңеп калды.

Тумышы белән Тәлгат абый хәзерге Татарстаныбызда муллыкка, байлыкка ирешкән иң күркәм районнарның берсе санала торган Нурлат-Октябрь туфрагыннан. Район үзәгеннән шактый ерак урнашкан, беренче карашка гади, ләкин сирәк, экзотик исемле Кычытканлы авылында бу якты дөньяга аваз салган ул, шул җирдә аның кендек каны тамган. Иван Явыз рухи мәркәзебез Казанны яулап, татар ханлыгының җирләрен басып алгач, борынгы әби-бабайларыбыз качып-посып, урманлы-кычытканлы урында бу гүзәл авылга нигез салганнар. Алар арасында акыллы, зирәк Галиуллалар нәселенең дә җиде буыны билгеле... Тәлгат абыйның бабайсын – Хафизулла улы Галиулланы – авылда “писарь” Галиулла дип йөрткәннәр, чөнки ул укымышлы гаиләдән чыккан, укый-яза белгән, мәдрәсәдә укыган, Карамал исемле күрше авыл чибәренә өйләнгән. Бу фани (вакытлы) җиһанда тормыш михнәтен күп күргән. Беренче Бөтендөнья сугышында катнашкан, телләр өйрәнүдә сәләте ачылган: фронтта урысча укырга, язарга, сөйләшергә өйрәнгән. Алман әсирлегенә эләккәч, дошман телен дә үзләштергән. Үзе кебек үк улы Нәбиулла да сугыш утыннан исән калган фронтовик, икенче малае хәбәрсез югалган. Татар халкының менталитетына хас булганча, мәгърифәт нурының яктылыкка илтүен тирән аңлаган, беренче карашка гади кибетче, әмма кан тамырларында татарга хас сәүдәгәрлек геннарын саклаган Нәбиулла абзый да балаларын укытып, олы тормыш юлына озаткан, кеше иткән. (Язучының тормыш юлы белән кызыксынучыларга аның “Гомер тәлгәшләре” автобиографик повестен [1] укырга тәкъдим итәм.)

Т.Н.Галиуллин белән иң әүвәлге очрашуым 1992 елның июль ахырында узган тантаналы җыелышта, Казан дәүләт университетының ул оештырган һәм шактый еллар җитәкләгән татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш

телләре факультетына тәүге сынауларны уңышлы үтеп, “Казан университеты студенты” дигән горур исемгә ирешкәч, декан кулыннан зәңгәрсу тышлы студент билеты алганда булды. Т.Н.Галиуллин шул көнне татар факультеты тарихында беренче һәм соңгы тапкыр рекордлы санга җиткән контингентның – бюджет урыннарына алынган 136 студент һәм тагын Татарстан Мәгариф министрлыгы (ул чакта министр Васыйл Гайфуллин) биргән квота нигезендә укырга кергән 40 студентның кулларын кысты. Безне алты төркемгә бүлделәр, арабызда Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Шәрәфиев Равил малае Вил, Татарстан халык артисты Гыймадиев Фердинат улы Илшат та бар иде.

Минемчә, мондый югары күрсәткеч 1990 еллар башында татар мәгарифенең ныклап күтәрелүенә, татар теленең дәүләт теле буларак, Татарстанда гамәлгә керә башлаган ул чорда ана телебез укытучыларына зур ихтыяҗ булуына нигезле дәлил. Бу эштә, һичшиксез, Т.Н.Галиуллинның саллы өлеше бар. Чөнки ул 1986 елда Алабугадан башкалабызга кайтып, ике ел Казан дәүләт педагогика институтының рус әдәбияты кафедрасында укыткач, КДУга күчә. Университет һәм халкыбыз тарихында беренче мәртәбә оештырылган татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре факультетын житәкли башлый, татар телен һәм әдәбиятын укыту методикасы кафедрасын оештыра. 1988–2000 елларда факультетның деканы булып эшләде, 2008 елга кадәр кафедра мөдире вазыйфасын башкарды.

Остаз буларак, Тәлгат ага – әдәпле, ипле, укымышлы фәнни җитәкче. Ул үз шәкерте белән дә җиңел аралаша: җайлы сөйләшә, нечкә юмор кушып, шаяртып та ала, фикереңне, теләгеңне ике сүздән аңлый. Аның холкындагы бу күркәм сыйфатлар, күрәсең, гомере буе студентлар арасында кайнавыннан, Алабуга дәүләт педагогика институтында 15 ел ректор, КДУда 12 ел декан булып эшләгәндә яшьләр дөньясын тирән аңлый белүеннән килә.

Студент чакта ул безгә “Хәзерге әдәбиятның актуаль проблемалары”, “Фәнни эшкә өйрәтү” дигән махсус курслар укытты. Ни гаҗәп, аның дәресенә барыбыз да йөрдек, 1112-нче аудиториядә биш төркем бергә, шыплап тутырган шырпы тартмасы кебек утыра идек. Мөгаен, кырыс холыклы, гадел кыяфәтле деканнан шүрләгәнбездер инде. 96 битле калын дәфтәргә лектор сөйләгәннең сүзен-сүзгә, тиз-тиз язып бардык. Остазга ихтирам йөзеннән ул лекцияләр дәфтәрен әле дә кадерләп саклыйм. Миңа калса, Т.Галиуллин кебек әйткән сүзенең тәмен белеп, аңлаткан темасы хакында ләззәтләнеп, бер сәгать егерме минут дәвамында илһамланып, тоташ бер тын белән лекция укучы галимнәр бик сирәк очрый.

Язмышыма рәхмәтлемен, бәхет Кояшым миңа КДУ аспирантурасында укырга һәм Т.Н.Галиуллин җитәкчелегендә “XX гасырның 80-90 елларында татар повесте (чор һәм автор образы)” дигән темага кандидатлык диссертациясе якларга насыйп итте. Аның кул астында эшләп, гыйльми хезмәт язуның нюансларына тагын да тирәнрәк төшендем.

Татар әдәбиятында 1980 елларның I яртысында “тормыш проблемаларын иҗтимагый һәм милли эчтәлекләре белән җитди итеп калкытып куярга сәләтле “татар повесте” формалашты”, – дип язды Т.Галиуллин “Тәнкыйть һәм әдәби процесс” исемле мәкаләсендә [2]. Вакыт галиҗанәпләре галимнең татар прозасында повесть жанры турындагы күзәтүләренең дөреслеген раслады.

Әдәбият галиме буларак, Т.Галиуллинны әдәбият гыйлеме фәнендә тирән энциклопедик белемле, киң эрудицияле, югары мәдәниятле, зыялы фән әһеле, дип саныйм. Акылы бик күпне сыйдырган шәхес ул. 1968 елда “Хәзерге татар поэзиясе һәм халык иҗаты” дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый.

“Доктор булуның ние бар...” публицистик язмасының (1994) “Алма-Атада татар десанты” дигән беренче бүлегендә галим үзенең докторлык диссертациясен 1981 елның октябрь аенда Казахстан башкаласында яклавы турында җентекләп яза.

“Кешенеке – кештәктә, үзеңне – үзәктә” исемле өченче бүлектә 1991 елның җәендә КДУның татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләр факультеты каршында төрки телләр һәм әдәбиятларыннан докторлык яклау Советы ачылу тарихын тасвирлап уза (рәис итеп ул чакта КДУда уку-укыту эшләре буенча проректор булып эшләгән күренекле тарихчы галим, татар филологиясе һәм журналистика факультетларын ачуга зур көч куйган М.Госманов тәкъдим ителә). Бу эш авырлык белән барган. Озакламый әдәбият белгече Т.Галиуллинны Советның рәисе итеп раслыйлар, хәзер ул үзе яклата, булачак докторларга уңай тавыш бирә. 1990 елларда Х.Й.Миңнегулов, Р.К.Ганиева, Ә.Нигъмәтуллин, Ф.Г.Гарипова, Х.Курбатов, Р.Әхмәтҗанов, М.Х.Бакиров, В.З.Гарифуллин, Ә.М.Сәхапов, Ф.З.Яхин, Д.Ф.Заһидуллина, И.Бәширова, Ф.Бәшир һ.б. олы уңышка ирештеләр.

“Илһам чишмәләре”, “Социалистик реализм юлыннан”, “Дыхание времени” монографияләрендә Т.Галиуллин 1920-1930 еллар татар шигърияте үсешен өйрәнә.

Аның беренче тәнкыйди язмалары 1960 еллар уртасында матбугатта күренә башлый. “Казан утлары” журналында “Поэманың барыр юллары”, “Балладаларыбыз турында”, “Шигъри ачышлар һәм югалтулар аша”, халык шагыйрьләре С.Хәким, Х.Туфан, И.Юзиев, Ш.Галиев, Р.Фәйзуллин, Р.Харис

шигъриятләрен фәнни анализлаган мәкаләләре басыла. “Еллар юлга чакыра”, “Яңа үрләр яулаганда”, “Безнең заман – үзе җыр”, “Дәвамлылык”, “Шагыйрьләр һәм шигырьләр”, “Шигърият баскычлары”, “Гомер учагы” җыентыклары Казанда, ә “Здравствуй, поэзия!” китабы Мәскәүдә дөнья күрә.

“Шигърият баскычлары”нда тәнкыйтьченең 1995-1999 елларда язылган “Милли үзаң һәм шигърият”, “Татар әдәбиятында “диссидентлар” булганмы?”, “Тарих мизгелләре яңарганда”, “Шагыйрьләр – изгеләр нәселеннән”, “Фикер һәм хис бердәмлеге” һ.б. әдәби тәнкыйть мәкаләләре тупланган. Галим “Татар поэзиясе тарихын яңача өйрәнү мәсьәләләре”, “Тукай һәм XX гасыр татар шигърияте”, “Тукай шигырьләрен яңача укыганда”, “Хәзерге татар шигърияте” дигән гыйльми язмаларында XX йөз шигъриятебезне яңача өйрәнә, аның үзенчәлекләрен бүгенге милли-мәдәни үсеш баскычыннан торып бәяли. Автор хәзерге шигърият диңгезендә зур колач җәеп, яхшы йөзә, аның фикеренчә, шигъриятгә һәрчак дәвамлылык булган, шигырьнең иң яхшы хасиятләре буыннан-буынга, гасырдан-гасырга күчә барган.

1990 елларда Т.Галиуллин публицистика, чәчмә әсәр жанрларында каләмен сынап карады: әдәбиятыбызда әйтер сүзе, үз фикере, үзенчәлекле стиле булган публицист һәм язучы итеп исбатлады үзен.

Публицистның мемуар жанрында иҗат ителгән “Замана балалары” (1993) тормыш күзәтүләренә бай истәлекләрдән, атаклы татар совет түрәләре Фикрәт Әхмәтҗан улы Тәбиев (русча Табеев), Гомәр Исмәгыйль улы Госманов (рус. Усманов), Рәис Кыям улы Беляевнең кылган гамәлләренә кырыс бәяләрдән, катлаулы заманыбыз турында уйланулардан тора. Язучы болгавыр чорда милләтебезне борчыган мөһим проблемаларны кыю рәвештә күтәрде.

“Дәгъва” (1995), “Шәхесне гасырлар тудыра” (2003) китаплары “Замана балалары”ның дәвамы санала. “Дәгъва”га авторның хикәяләре, публицистик, әдәби тәнкыйть мәкаләләре тупланган. Басмага кергән “Хаҗга зыярәт шәхси эшме?” (1993), “Кияү” каласында Сабантуй” (1994) язмалары сәяхәтнамә жанрында иҗат ителгән, дип уйлыйм. Соңгысында сүз “Бөтендөнья татар конгрессы” Башкарма комитетының беренче рәисе Иидус Риза улы Таһиров белән бергә Украина башкаласы Киевкә барулары һәм җирле татарлар оештырган Сабантуйда катнашулары хакында бара.

“Хаҗга зыярәт шәхси эшме?” сәяхәтнамәсенең “Кеше күңеле – таш түгел” дигән өченче бүлегендә Т.Галиуллин моннан унбиш ел элек болай дип язган:

“Ислам диненә табынган илләрнең берсе дә Ауропада урнашкан бердәнбер мөселман иле – Татарстанны рәсми танырга ашыкмавы да күп

нәрсә турында сөйли. Әйе, безнең көннәрдә ислам кыерсытылган, кысылган, идән асты дине булудан туктады, түләүле атеистлар армиясе һөнәрен алыштырды. Дин әһелләре, мәчетләр, ачыла килгән мәдрәсәләр, хөррият һәм азатлык шартларында, башка ышанулар белән көрәштә яшәргә, үсәргә әзерме?

Коръәнне су кебек эчкән, заманча аңлата белгән, үткен сүзе белән туң йөрәкләрне эретә алырлык вәгазьчеләребез бармы? Гомумән, дингә чын күңелдән ышанган, табынган, аңа җанын-тәнен салган, дөнья мәшәкатьләренә артык игътибар бирми торган шәхесләребез күпме?” [3, 119 б.]

Автор куйган бу сораулар бүген дә мөһимлеген югалтмый. К.Шәриф мәчете имам-хатыйблары Рамил хәзрәт Юныс һәм Рөстәм хәзрәт Зиннуров, Татарстан мөселманнарының баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев кебек оста вәгазьчеләребез бармак белән генә санарлык әле һаман да.

Шушы ук язманың “Каерылган аккош канаты” исемле бишенче бүлегендә Т.Галиуллин 1993 елның 12-16 июлендә КДУ белән Алманиянең Гиссен университеты галимнәре үткәргән уртак фәнни җыен турында яза. Конференциядә катнашкан алман профессоры А.Хампельнең Югославиядәге кан коеш һәм Босния мөселманнары язмышы турындагы чыгышы барыбызны да сискәндерде, ди галим. Чыннан да, Балкан ярымутравындагы олы сәясәт темасы, аерым алганда, 2008 елның 17 февралендә бәйсезлек игълан иткән Косово тирәсендәге шау-шу хәзер дә актуаль.

Тәлгат Галиуллин, аерым алганда, хикәя жанрында да нәтиҗәле эшләде. “Кияү”, “Туган көн”, “Урман хуҗасы”, “Ниткән хат ул?”, “Абу”, “Һавада “татарин”, “Ышанычымны акламадыгыз!”, “Суган суфые”, “Колючник”, “СПИД вә мәхәббәт”, “Дәгъва”, “Ура, таптык!” хикәяләрендә чынбарлыкта булган вакыйгаларны сурәтләде.

Автор “Кияү” хикәясендә (1994) Аксубай районында туып үскән мишәр егете Сәгыйрьнең башка татар егетләренә дә гыйбрәт алырлык аяныч язмышын тасвирлый. Ул Украинаның Львов шәһәренә армиядә хезмәт итәргә җибәрелә. Анда аны тумышы белән себер татары, майор дәрәҗәсеннән артык үстерелмәгән Биктимер (Борис) Загретдинов, хатыны Феоктиста Петровна ярдәменә таянып, тиз арада кармакка төшерә – җилбәзәк кызлары Светага өйләндереп куя. Беркатлы Сәгыйрь, мәсьәләнең асылын аңлап бетергәнче үк, шул рәвешле, кияүгә әйләнә. Татарча белмәүче, өйрәнергә дә теләмәүче, ашарга пешерергә ялкау, чит ирләр куенына керергә яратучы, азгын хатын белән тормыш башлана. Озакламый Казанга күчеп кайталар, ир хәрби заводка эшче булып урнаша, институтка читтән торып укырга керә. Светланасы аңардан акча алып кайтуын гына көтә. Русча гына сөйләшүче ике малай

үстерәләр... Карл исемле олы уллары бабайсы юлыннан китеп, Балашово хәрби уку йортында белем ала. Кечесе Ромео шайкада йөреп, квартира басып, балалар колониясенә элэгә. Биктимер абый кинәт кенә үлеп китә.

...Аннары аерылышу. Катнаш никах таркала. Хатыны квартираны бүлеп, әнисе янына, Оренбург өлкәсенә китеп бара. Ялгыз яшәп туйган Сәгыйрьне абыйлары ирдән аерылган Әсма исемле хатынга өйләндерәләр. Ул авылда укытучы булып эшли, аның бер кызы – Гөлнисасы бар. Димләгәч, Сәгыйрь янына, шәһәргә күчеп килә. Яңа гаиләгә ике бүлмәле квартира да бирәләр. Тормышлары җайлашып беткәч генә, бәллүр савыт чәлпәрәмә килә. Колониядән кайткан Ромео да алар белән бергә яши. Язгы кояшлы көннәрнең берсендә ул Гөлнисаны көчли. Сабыр холыклы Әсма кызын ияртеп, бозыклык, әхлаксызлык оясын – шәһәрне ташлап, туган авылына кайтып китә. Сәгыйрь тагын берүзе кала.

“Бүгенге газапларның тамыры кичәге шатлык иде. Шатлык уртак була. Ә кайгы кешеләрне гел аерым-аерым эзләп йөри икән шул”, – дип тәмамлый язучы хикәясен. Сәгыйрь тормышы – башка милләт хатын-кызына өйләнү, йортка керү, гаилә башлыгы була белмәүнең ачы мисалы ул.

Җыеп әйткәндә, хикәяченең сурәтле фикерләвенә үткән заман хәлләре хакында хәзерге чор позициясендә торып уйлану, аларны дөрес бәяләү, язучы теленә исә җиңелчә шаярту, йомшак һәм ачы көлү хас. Бу яктан мин аның язу стилендә, фикерләү сөрешендә И.А.Бунин, М.С.Мәһдиев, А.М.Гыйләҗев иҗатларына хас уртак чалымнар, уй-хис бергәлеген тоям.

Тәлгат Галиуллин үзен роман жанрында да уңышлы сынады: кызган табадан төшкән кайнар коймак шикелле “Тәүбә” (1996), “Элмәк” (1997), “Төнге юллар” (2003) романнары бер-бер артлы басылып торды. Нәтиҗәдә үзен сәләтле прозачы итеп танытты. Ниһаять, безнең милләт тә бу роман-трилогия йөзендә үз тормышының лаеклы чагылышын тапты.

Гомумән, 1990 еллар татар прозасында роман жанры да җанланды. Моңа күз йомып булмый. Бу күренеш бигрәк тә 1996-1997 елларда көчәйде. Мәсәлән, шул ук 1997 елда “Казан утлары” журналының 1-8 саннарында бер генә повесть тә юк. Сан саен татар романнары тезелеп киткән: Т.Галиуллин “Элмәк”, К.Миңлебаев “Бакый”, Зөлфәт “Гөнаһ”, Р.Сибат “Исабәт”.

Шулар арасында аеруча Т.Галиуллин, Зөлфәт романнары җылы кабул ителде. Ни өчен? Чөнки татар укучысы моңарчы рус телендә басылган Александр Гуровның “Красная мафия”, “Я – вор в законе” әсәрләре һәм Италия, Америка мафиозилары турындагы документаль китаплары, талантлы милләттәшебез Рауль Мир-Хәйдәровның гомуми тиражы 5 миллион данәгә җиткән “Пешие прогулки” (1988), “Двойник китайского императора” (1989),

“Масть пиковая” (1990), “Судить буду я” (1992), “Ранняя печаль” (1996), “За всё – наличными” (1997) романнары белән таныш булса да, милли әдәбиятыбызда әлеге мохитны үзәккә алган әсәрләр юк дәрәҗәсендә иде. Шуңа күрә татар-рус мафиясе, замана байлары хакында үз ана телендә укырга сусаган укучыбыз Тәлгат Галиуллинның “Тәүбә”, “Элмәк”, “Төнге юллар” романнарын бик көтеп алды. Бу әсәрләрнең әдәби-эстетик кыйммәте – бүгенге тормышта байлыкка, акчага табыну проблемасын кыю яктыртуда, татар әдәбиятында базар икътисады, эшмәкәрлек, эшкуарлар дигән яңа теманы күтәреп чыгуда, прозабызда яңа тип саналучы Сәет Сакманов исемле замандашыбызның каршылыклы образын тудыруда, аның характерын ачуда. Миңа калса, геройның прототибы – итальян, американ фильмнары үрнәгендә, 1990 елларда Алабуга янында, “вольво” машинасында атып үтерелгән Татарстан Югары Советының элеккеге депутаты, алыпсатар Сәид Гафиатуллин [3, 125 б.].

Равил Габдрахман улы Фәйзуллинның “Сайланма әсәрләре”нең V томлыгы чыгу уңаеннан язылган “Ташларны барлар вакыт” мәкаләсендә әдип-публицист Тәлгат Галиуллин халык шагыйренең әдәби-публицистик мәкаләләре, иҗат портретлары, әңгәмәләре, эссе-уйланулары турында фәлсәфи фикер йөртә, рухи-сәяси күзәтүләр ясый. “Татар мәктәп-гимназияләребезнең саны да, сыйфаты да канәгатьләндерми, күп очракта күз буяу, үзебезне алдау фарсыннан уза алмый. Шәһәрләрдә, хәтта авылларда мәктәп хуҗалары, укытучылар татар мәктәпләренә балаларны зур авырлык белән җыялар, тагын да зуррак тырышлык илә саклап тоталар.

Әлбәттә, моның төп сәбәбе итеп Мәскәүне атыйбыз (анысы да хак), үзебезнең 90 нчы еллар башында бирелгән форсаттан файдаланып кала алмавыбыз, мәңге шулай иркенлек булыр дип авыз ачып йөрүебез турында онытабыз. Шул елларда татарларны башка төбәкләрдән кайтарырга, милли университетны ачып, яшәп килүче югары уку йортларында татарча укытуны кертеп, ректорлар сафын төп милләт вәкилләре исәбенә баетып була иде...” [4].

Галим-публицист “Тарихыңны онытсаң – юк киләчәгең...” дигән мәкаләсендә (1992) Рабит Батулланың “Сөембикә кыйссасы” романы, Әхмәт Рәшитовның “Сөембикәнең Казан халкы белән хушлашуы” поэмасы, Флүс Латыйфинең “Хыянәт” тарихи романына һәм билгесез рус елъязмачысының “Казан патшалыгы турында кыйсса”сына (профессор Н.Водовозов аны хәзерге рус теленә тәрҗемә итеп, 1959 елны бастыра) төпле бәя бирә [5].

Татарстанның халык язучысы Гариф Ахунов әйткәнчә, Тәлгат Галиуллинның “эшләгән эше таулар кадәр” [6]. Ун гасырдан артык бөек тарихы булган татар әдәбияты аны олы шәхес итеп тудырды.

Т.Галиуллин, кайбер мактанчык, борыны күтәренке “профессорлар”дан аермалы буларак, вакчыл галим түгел. Ул андыйлардан ике башка югары тора. Ул – тузга язмаган сүзләрдән, төрле гайбәтләрдән өстен кеше. 1986 елда аны кара көнчеле хезмәттәшләренең гайбәте – шикаяте – аркасында ректорлыктан алганнар. Ул – үз дәрәҗәсен яхшы белүче, горур кыяфәтле, баш бирмәс зат.

Тәлгат Галиуллинда пассионарлык энергиясе кайнап, ташып тора. Ул – хәзерге татар әдәбият белеме фәнендә әйдәп баручы галим, башкаларны үз артыннан ияртүче лидер. Конкрет фәнни проблеманы чишү өчен үз тирәсенә яшь белгечләрне туплый белә. Поляк-совет магы Вольф Мессинг кебек аудиторияне кулда тота: ул сөйләгәндә галим-голәмә, студент-аспирантлар аның авызына гына карап тора, чыгыш ясаганда аны зур игътибар белән тыңлыйлар.

Тәлгат абый белән кара-каршы утырып, әдәбият дөньясы һәм язучыларның бүгенге аяныч хәлләре, милләт эшләре турында яки сәяси темаларга иркенләп, тәмләп сөйләшеп була. Ул, чыннан да, кешеләрдән ялыкмый, чөнки аралашырга ярата. Күп сөйләп башкаларны да туйдырмый. Ул – кызыклы, белемле әңгәмәдәш. Сине бүлдермичә игътибар белән тыңлый белә, теге яки бу мәсьәлә буенча саллы сүзен әйтә, проблеманы хәл итү юлларын күрсәтә, кирәк чакта дөрес киңәш бирә, көлдереп алырга да онытмый...

Галимнең әдәби тәнкыйть мәкаләләрендә тикшерену объектына эләккән урта һәм өлкән буын әдипләрнең үзләренә дә, әсәрләренә дә гадел хөкем чыгарыла, яшь шагыйрьләр дә үз иҗатларына карата аның хак бәясен алуга өметләнәләр.

Бар булмышыгыз һәм әзер калыпларга, рәсми кысаларга сыймаган шундый Тәлгат Галиуллин булуыгыз өчен, шулай зыялыча яшәвегез һәм рыцарьча көрәшүегез өчен, кыю, тирән фикерле фәнни-публицистик мәкаләләрегез белән вакыт-вакыт милләтебезне сискәндереп чаң сугуыгыз өчен, кыскасы, Тәлгатлыгыз өчен мең рәхмәтле без сезгә!

Мөхтәрәм Тәлгат Нәбиулла улы бүген дә иҗади хыяллар белән яши, яңа әдәби әсәрләр яза. Остазым, Аллаһы Тәгалә сезгә үзенең илһам чишмәсеннән тәнгә шифалы, сихәтле суын эчертеп, иҗат канатларыгызны тагын да ныгытсын, киләчәктә дә иҗат чишмәләрегез мул булып, ургылып аксын!

## Кулланылган әдәбият


1. Галиуллин Т.Н. Гомер тәлгәшләре: автобиографик повесть һәм хикәяләр. Урта һәм олы яшьтәге мәктәп балалары өчен. – К.: Мәгариф, 1999. – 191 б.

2. Галиуллин Т.Н. Дәвамлылык. – К.: Татар. кит. нәшр., 1987. – 152 б.

3. Галиуллин Т.Н. Дәгъва: Хикәяләр, публицистика, әдәби тәнкыйть. – К.: Татар. кит. нәшр., 1995.

4. Галиуллин Т.Н. Ташларны барлар вакыт // Равил Фәйзуллин: Заман. Иҗат. Шәхес / Төзүче һәм кереш сүз авторы Зиннур Мансуров. – К.: Мәгариф, 2002. – 228–229 б.

5. Галиуллин Т.Н. Тарихыңны онытсаң – юк киләчәгең... // Сүнмәс утлар балкышы. Мең санлы хәзинәдән: Әдәби-нәфис басма / Төзүчесе Рәфикъ Юныс. – К.: “Идел-Пресс” полиграфия-нәшрият комплексы, 2006. – 23–25 б.

6. Ахунов Г. Эшләгән эше таулар кадәр // Галиуллин Т.Н. Шигърият баскычлары: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – К.: Мәгариф, 2002. – 226 –229 б.

Учебное издание

Фаттахов Ильгам Фаилевич

**Секреты мастерства писателя**

Учебное пособие

Корректор ?